# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 7*
*июль*
*(I өлеш)*
*2012*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2012

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ  78696
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 $^{1}/_{16}$. Тираж 150 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2012

Эчтәлек

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР


960. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....12

961. «Сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать тукلануы урыннарын билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....15

962. «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....16

963. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....17

964. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....18

965. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....22

966. «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....25

967. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....31

968. «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» Татарстан Респуб-

ликасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................................32

969. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........35

970. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................................................53

971. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .........64

972. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................................66

973. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........72

974. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына

үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................74

975. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................82

976. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................112

977. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................113

978. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................115

979. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........116

980. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................118

981. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышы каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............119

982. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6372-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......123

983. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (6372-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .............124
984. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (1370-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........124
985. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4400-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........................................125
986. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4400-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................................125
987. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4393-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................126
988. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4393-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....................126
989. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5394-4 номерлы Татар-

стан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....127

990. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (5394-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............127

991. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5395-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...........128

992. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (5395-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................................128

993. «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 6375-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........................................129

994. «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (6375-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........................................................................129

995. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2399-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .........................................................................130

996. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................................131

997. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме турында» 7404-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............................131

998. «Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы нотык хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...........132

999. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........133

1000. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....134

1001. «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....139

1002. «Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Елизаветино авылының исемен үзгәртү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .........144

1003. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 66075-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның аерым нигезләмәсен төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................................................145

1004. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 62372-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә хокуклы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....................................145

1005. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 67447-6 номерлы федераль закон

проекты турында (нефть продуктлары әйләнеше өлкәсендә планлы тикшерүләр үткәрүнең даимилеген арттыру турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................146

1006. «Электр белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә тарифлар белән җайга салуны камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 82041-6 номерлы федераль закон проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ......147

1007. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проекты хакында (файдалануга тапшырылган күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген тәртипкә салу һәм төзелеш алып баручыга торак урынын тоткан һәм ремонтлаган өчен һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү кертүнең хокукый нигезләрен булдыру турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................147

1008. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 82033-6 номерлы федераль закон проекты хакында (коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын эшләүгә һәм раслауга таләпләр билгеләү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................148

1009. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына шәһәр төзелешен проектлау буенча региональ һәм җирле нормативлар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 86567-6 номерлы федераль закон проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................149

1010. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......149

1011. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексының 17 һәм 223 статьяларына төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче төзелеш алып баручыларның банкротка чыгу үзенчәлекләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................150

1012. «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 85076-6 номерлы федераль закон проекты турында (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме кертү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................151

1013. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 62063-6 номерлы федераль закон проекты турында (1927 елның 4 сентябреннән 1945 елның 3 сентябренә кадәр чорда туган гражданнарны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................151

1014. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 59048-6 номерлы федераль закон проекты турында (1931 елның 31 декабренә кадәр туган затларны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында (сугыш елларындагы эш стажын расламыйча гына)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................152

1015. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 89417-6 номерлы федераль закон проекты турында (Интернет челтәрендәге хокукка каршы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген чикләү мәсьәләсе буенча)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...153

1016. «Дару чаралары әйләнеше турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проек-

тын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....153

1017. «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....154

1018. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Ярославль өлкә Думасы мөрәҗәгате турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...........................155

1019. «Инвалид бала караучы хезмәткә сәләтле эшләмәүче затларга айлык компенсация түләве күләмен арттыру мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........................155

1020. «Ювениль ревматоид артриттан интегүче балаларны ген-инженерия биологик препаратлары рәвешендәге дәвалау чаралары белән тәэмин итү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................156

1021. «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга, Россия Федерациясе Эчке эшләр министры В.А. Колокольцевка һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .............157

1022. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимов гарызнамәсе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .............157

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 960. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 8 – 9; 2002, № 2; 2004, № 4 – 5; 2006, № 6 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 19 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Дәүләт гражданнарга дәүләткә карамаган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә, шулай ук дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем алуда ярдәм итүне Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренең уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү нормативлары нигезендә тиешле федераль дәүләт мәгариф стандартлары һәм (яисә) федераль дәүләт таләпләре чикләрендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетларыннан кирәкле күләмдә бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән башкара.»;

2) 29 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пунктча өстәргә:

«$11^1$) дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү учреждениеләрендә гражданнарның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем алуын Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренең уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү нормативлары нигезендә педагогик хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны, дәреслекләргә һәм уку-укыту әсбапларына, укыту-күрсәтмә әсбапларга, укытуның техник чараларына, уеннарга, уенчыкларга, кирәк-ярак әйберләргә чыгымнарны финанслау өлешендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә финанс белән тәэмин итү;»;

3) 30 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пунктча өстәргә:

«$2^1$) дәүләткә карамаган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларның белем алуын муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен билгеләнгән нормативлар нигезендә педагогик хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны, укыту-күрсәтмә әсбапларга, укытуның техник чараларына, уеннарга, уенчыкларга, кирәк-ярак әйберләргә чыгымнарны финанслау өлешендә мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә финанс белән тәэмин итү;»;

4) 37 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү учреждениеләрендә гражданнарның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем алуын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

5) 47 статьяның 5 пунктында «балаларын карап тоту өчен» сүзләреннән соң «(балаларын карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләрен өстәргә;

6) $47^1$ статьяда:

а) статьяның исемендә «баланы карап тоту өчен» сүзләреннән соң «(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктта «баланы карап тоту өчен» сүзләреннән соң «(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта:

«баланы карап тоту өчен» сүзләреннән соң «(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләрен өстәргә, «баланы карап тотуга» сүзләреннән соң «(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләрен өстәргә;

«чикләнгән балаларны» сүзләрен «чикләнгән балаларны карап тоту өчен (балаларны карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләренә алмаштырырга;

«балаларны карап тоту өчен» сүзләреннән соң «(балаларны карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләрен өстәргә;

г) 3 пунктта «баланы карап тоту өчен» сүзләреннән соң «(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 9 июле
№ 43-ТРЗ

## 961. «Сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннарын билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннарын билгеләү тәртибе турында» 2010 елның 31 декабрендәге 128-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 9 июле
№ 44-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 962. «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда «опека һәм попечительлек мәсьәләләрен» сүзләрен «опека, попечительлек һәм патронаж мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның беренче өлешендәге дүртенче абзацта «попечительлеккә» сүзен «патронажга» сүзенә алмаштырырга;

3) 4 статьяның өченче абзацында «һәм попечительлеккә» сүзләрен «, попечительлеккә яисә патронажга» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяда:

а) икенче абзацта «яисә попечительлеккә» сүзләрен «, попечительлеккә яисә патронажга» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта «патронаж рәвешендә попечительлек билгелиләр» сүзләрен «патронаж билгелиләр» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта «һәм попечительләр» сүзләрен «, попечительләр һәм ярдәмчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

г) егерме өченче абзацта «, шулай ук ярдәмченең үз вазыйфаларын үтәвен тикшереп торалар» сүзләрен өстәргә;

5) 7 статьяның икенче өлешендә «балигъ булган затларны һәм сәламәтлеге буенча хокукка сәләте булып та үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашыра һәм яклый алмаган, үз бурычларын үти алмаган затларны попечительлеккә алу» сүзләрен «балигъ булган затларны попечительлеккә алу һәм сәламәтлеге буенча хокукка сәләте булып та үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә

ашыра һәм яклый алмаган, үз бурычларын үти алмаган затларны патронажга алу» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 9 июле
№ 45-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 963. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгә-реш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яисә таралу өчен шартлар булган һәм сакланып кала торган территорияләрдә һәм урыннарда лаборатор тикшеренү ысулларын кулланып уздырыла торган дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар (алга таба – эпидемиягә каршы чаралар) үткәрү буенча гамәлләр башкаруны оештыру;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 9 июле
№ 46-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 964. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) спортның уникальлеген, аның социаль һәм белем бирү функцияләрен, шулай ук аның субъектларының ихтыярый эшчәнлегенә нигезләнгән структурасы үзенчәлекләрен исәпкә алып, спортның барлык төрләре һәм состав өлешләре, шул исәптән балалар-яшүсмерләр спорты, мәктәп спорты һәм студентлар спорты үсешенә ярдәм итү.»;

2) 5 статьяның 1 пунктында «спорт әзерлеге үзәкләре,» сүзләреннән соң «студентларның спорт лигалары,» сүзләрен өстәргә;

3) 6 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$) Татарстан Республикасы төзегән һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның, шулай ук Татарстан Республи-

касы территориясендә урнашкан, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекләр катнашыннан башка төзелгән һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның федераль спорт әзерлеге стандартларын үтәвен Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшереп торуны гамәлгә ашыру;»;

б) 2 өлештә:

2 пунктта «укыту-тренировка» сүзен «тренировка» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта «балалар-яшүсмерләр, яшьләр спорты,» сүзләрен «балалар-яшүсмерләр спорты, мәктәп спорты, студентлар спорты,» сүзләренә алмаштырырга;

4) 9 статьяның 2 өлешендә «укыту-тренировка» сүзен «тренировка» сүзенә алмаштырырга;

5) 11 статьяда:

а) 1 өлештә «укыту-тренировка» сүзен «тренировка» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Мәктәп спорт клубларының һәм студентлар спорт клубларының хокукый хәле, аларның эшчәнлек тәртибе Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.»;

6) 18 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$) спортчы спорт әзерлеге узган оешмалар һәм мондый әзерлекнең дәвамлылыгы турында белешмәләр;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Затның спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмасына каравы спорт әзерлеге буенча хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт йөкләмәсе (муниципаль йөкләмә) яисә спорт әзерлеге буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәсе нигезендә спорт әзерлеге узу өчен затны мондый оешмага кабул итү турындагы боерык нигезендә билгеләнә.»;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Спортчы, спорт әзерлеге узучы зат мәгариф учреждениесенә кабул ителгән һәм спортчы белән әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән шартнамә төзелмәгән булса, ә спорт әзерлеге узучы затка карата әлеге статьяның $3^1$ өлешендә күрсәтелгән боерык булмаса, спортчының, спорт әзерлеге узучы затның мәгариф учреждениесенә каравы

мәгариф учреждениесенә кабул итү турында боерык нигезендә билгеләнә.»;

7) 19 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9) мәктәп спортын һәм студентлар спортын үстерүгә һәм популярлаштыруга ярдәм итү.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү, урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре, белем алучыларны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, мәктәп спортын һәм студентлар спортын үстерү һәм популярлаштыру максатларында, юридик затлар булмаган мәктәп спорт клубларын һәм студентлар спорт клубларын (шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр рәвешендә) төзи алалар. Мондый спорт клубларының эшчәнлеге федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла.»;

8) 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. **Спорт әзерлеге**

23 статья. **Спорт әзерлеге этаплары. Федераль спорт әзерлеге стандартлары**

1. Спорт әзерлеге этаплары Федераль закон белән билгеләнә.

2. Федераль спорт әзерлеге стандартларын эшләүне оештыру һәм раслау Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

24 статья. **Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар**

1. Татарстан Республикасында спорт әзерлеге физкультура-спорт оешмалары, шул исәптән спорт әзерлеге үзәкләре, шулай ук физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләре, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре тарафыннан башкарыла. Республиканың спорт әзерлеге үзәкләре, тиешле спорт төрләре буенча бөтенроссия спорт федерацияләренең фикерләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы

тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә төзелә.

2. Затларны Татарстан Республикасы яисә муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмаларына кабул итү тәртибен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы билгели.

3. Затларны спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмаларына кабул итү кагыйдәләре спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмасын гамәлгә куючы, гамәлгә куючылар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә һәм аның уставында беркетелә.

25 статья. **Спорт әзерлеген гамәлгә ашыруга контроль**

1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан федераль спорт әзерлеге стандартлары үтәлешенә контроль Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Бөтенроссия спорт федерацияләре һәм республиканың аккредитация узган спорт федерацияләре һәм аларның вәкилләре спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан тиешле спорт төрләре буенча федераль спорт әзерлеге стандартлары үтәлешенә җәмәгать контролен башкарырга хокуклы.»;

9) 29 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Спорт чараларында катнашуга медицина ягыннан каршы күрсәткечләр исемлеге Федераль закон нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 9 июле
№ 47-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 965. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 5 өлешендә:

а) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен белгечлек буенча дәүләт хезмәте стажына яисә эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре билгеләнми.»;

2) $11^2$ статьяда:

а) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. 1, 2 яисә 3 класслы Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесенең класслы чиннары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан түбәндәгечә бирелә:

1) Татарстан Республикасы министрлыкларында һәм дәүләт комитетларында – шушы органнарның җитәкчеләре тәкъдиме буенча, Татарстан Республикасы вәкиллекләрендә – Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарында – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдиме буенча;

2) Татарстан Республикасының бүтән дәүләт органнарында – шушы органнарның җитәкчеләре тәкъдиме буенча.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 18 өлеш өстәргә:

«18. Әлеге статьяның 7 өлешендә һәм 8 өлешенең 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән классы чиннарны квалификация имтиханын уздырмыйча бирү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү тәртибе – имзасы белән тәкъдим кертелә торган дәүләт органы җитәкчесе (вазыйфаи заты) тарафыннан, ә әлеге статьяның 8 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән классы чиннарны бирү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү тәртибе шушы классы чиннарны бирүче Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.»;

3) 15 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) үзе һәм гаилә әгъзалары турында федераль закон белән каралган белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;»;

4) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. **Дәүләт хезмәтендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу**

1. Дәүләт хезмәтендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу һәм булдырмый калу тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.

2. Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы дәүләт органында, дәүләт хезмәтенә идарә буенча дәүләт органында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу өчен дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссияләр (алга таба – мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу комиссиясе) төзелә.

3. Мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу комиссиясе федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт органының хокукый акты белән төзелә.

4. Мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу комиссияләре комиссияләр тарафыннан кабул ителә торган карарларга тәэсир итәрлек мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп төзелә.»;

5) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

«6[1]. Дәүләт хезмәткәре тарафыннан үзенең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең яисә хатынының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмау, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, йә күрәләтә дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтеннән азат итүгә китерерлек хокук бозу була.»;

6) 28 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «урындагы» сүзен «хезмәттәге» сүзенә алмаштырырга;

7) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 29[1] статья өстәргә:

«29[1] статья. **Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу һәм җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларын үтәмәгән өчен түләтүләр**

1. Дәүләт хезмәткәре чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу һәм җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән, коррупциягә каршы көрәш максатларында федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен Федераль закон белән каралган түләтүләр салына.

2. Коррупцион хокук бозулар өчен түләтүләрне куллану тәртибе Федераль закон белән билгеләнә.»;

8) 45 статьяда:

а) 8 өлештә «гражданның гаризасы буенча» сүзләреннән соң «, шул исәптән электрон документ рәвешендә,» сүзләрен өстәргә;

б) 10 өлештә «гариза» сүзеннән соң «, шул исәптән электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

в) 11 өлешнең икенче абзацында «яки аларның гаризасы буенча» сүзләреннән соң «, шул исәптән электрон документ рәвешендә,» сүзләрен өстәргә;

г) 12 өлешнең икенче абзацындагы беренче җөмләсендә «пенсионерның гаризасы» сүзләреннән соң «, шул исәптән электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә.

**Статья 2**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 12 июле
№ 48-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 966. Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закондагы (алга таба – Федераль закон) мәгънәсендә кулланыла.

3. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салуның хокукый нигезен Федераль закон, бүтән федераль законнар, Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге муниципаль норматив хокукый актлар тәшкил итә.

2 статья. **Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Татарстан Республикасы**

**дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә законнар белән җайга салу;

2) Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә законнар үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә бүтән вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыру.

2. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт сәясәтен үткәрү һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

2) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын ачыкланган тәртиптә билгеләү;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үзара мөнәсәбәтләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә оештыру;

4) бүтән вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыру.

3. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнашу;

2) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә республика программаларын раслау;

3) күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәтенә карата энергияне сак тоту һәм энергетика

нәтиҗәлелеген арттыру буенча мәҗбүри чаралар исемлеген билгеләү;

4) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә республика программалары үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

5) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә бүтән вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыру.

4. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә республика программаларын эшләү һәм аларны тормышка ашыруны тәэмин итү;

2) федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары белән мәҗбүрилеге билгеләнгән, шулай ук энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге республика программасында каралган энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат ягыннан тәэмин итү;

3) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын координацияләү һәм Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре, дәүләт унитар предприятиеләре тарафыннан аларның үткәрелүен тикшереп тору;

4) Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнар таләпләренең үтәлешен республика дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру;

5) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә бүтән вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыру.

5. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның товарларына, хезмәт күрсәтүләренә бәяләр (тарифлар) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән очракта, мондый оешмаларның энерги-

яне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программаларына карата таләпләр кую;

2) кулланучылар өчен энергетика ресурсларына бәяләр (тарифлар) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан җайга салынган очракта, мондый ресурсларны халык тарафыннан куллануның социаль нормаларын билгеләү;

3) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә бүтән вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыру.

6. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программалар эшләү һәм аларны тормышка ашыру;

2) товарларына, хезмәт күрсәтүләренә бәяләр (тарифлар) җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнергә тиешле коммуналь комплекс оешмаларының энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программаларына карата таләпләр билгеләү;

3) федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән мәҗбүрилеге билгеләнгән, шулай ук энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге муниципаль программада каралган энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын мәгълүмат ягыннан тәэмин итү;

4) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын координацияләү һәм муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан аларның үткәрелүен тикшереп тору.

3 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт ярдәменең төп юнәлешләре һәм рәвешләре**

1. Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт ярдәме түбәндәге төп юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

1) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Татарстан Республикасының инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру;

2) энергетика сервисы шартнамәләрен (контрактларын) куллануны пропагандалау;

3) югары энергетика нәтиҗәлелегенә ия объектлар, технологияләр эшләүдә һәм куллануда булышлык итү;

4) югары класслы энергетика нәтиҗәлелегенә ия күпфатирлы йортлар төзүдә булышлык итү;

5) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге, аерым алганда, энергияне сак тотуның һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруның максатчан иң югары күрсәткечләренә ирешү күздә тотыла торган муниципаль программаларга ярдәм күрсәтү;

6) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарын үстерүне стимуллаштыру;

7) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген һәм энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларына мәгълүмат ягыннан ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыруга булышлык итү;

8) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы гамәлдәге законнарда каралган бүтән юнәлешләр.

2. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәме салымнар һәм җыемнар турында законнарда каралган стимуллаштыру характерындагы гамәлләрне кулланып, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген башкару, инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар, заемнар буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен каплау юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

4 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру гамәлләрен мәгълүмат ягыннан тәэмин итү**

Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын мәгълүмат ягыннан тәэмин итү дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан даими рәвештә түбәндәге юллар белән башкарылырга тиеш:

1) физик затларның Федераль законда билгеләнгән хокуклары һәм бурычлары турында, торак йортлар милекчеләренә, күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә, күпфатирлы йортларны карап тоту өчен җаваплы затларга карата куелган таләпләр хакында һәм Федераль законндагы бүтән таләпләр турында мәгълүмат таратуны тәэмин итү;

2) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә социаль реклама таратуны тәэмин итү;

3) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге республика һәм муниципаль программаларны һәм аларны тормышка ашыру барышы турында массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару;

4) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары һәм ысуллары турында, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә, шул исәптән чит илләрдә, ирешелгән аерым казанышлар һәм бу өлкәдәге бүтән мөһим мәгълүмат хакында массакүләм мәгълүмат чараларында тематик теле- һәм радиотапшырулар, мәгълүмати-агарту программаларын таратуны оештыру;

5) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларына урнаштыру һәм аны Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган кагыйдәләр нигезендә кимендә кварталга бер тапкыр яңарту;

6) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнар нигезендә бүтән гамәлләрне башкару.

5 статья. **Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге чараларны финанслау**

Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге чараларны финанслау энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге республика программаларын гамәлгә ашыру кысаларында киләсе финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган күләмнәрдә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында тыелмаган бүтән чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 49-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 967. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 17 гыйнвар, 20 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы өлеш өстәргә:

«Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 3.6 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасының Экология һәм табигать байлыклары министрлыгының вазыйфаи затлары Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләрне башкарганда төзергә хокуклы.»;

2) унынчы өлешне унберенче өлеш дип санарга һәм «алтынчы» сүзеннән соң «, унынчы» сүзен өстәргә;

3) унберенче өлешне уникенче өлеш дип санарга;

4) уникенче өлешне унөченче өлеш дип санарга һәм анда «тугызынчы» сүзен «унберенче» сүзенә алмаштырырга;

5) унөченче өлешне ундүртенче өлеш дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 50-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 968. «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» 2008 елның 22 ноябрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 2; 2011, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары, аудиторлары вазыйфалары муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән

муниципаль вазыйфаларга кертелгән очракта, әлеге вазыйфалар муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелми.»;

2) кушымтада:

а) I кисәкнең 3 бүлегендә:

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе*;»;

2 пунктның өченче абзацында «тикшереп тору» сүзләрен «контроль-хисап» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы.»;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы.»;

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«контроль-хисап органы аппараты инспекторы.»;

түбәндәге эчтәлекле сноска өстәргә:

«* Контроль-хисап органы рәисеннән гайре.»;

б) II кисәкнең 7 бүлегендә:

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең башка органы Җитәкчесе**;»;

2 пунктның алтынчы абзацында «тикшереп тору» сүзләрен «контроль-хисап» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы.»;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы.»;

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«контроль-хисап органы аппараты инспекторы.»;

түбәндәге эчтәлекле сноска өстәргә:

«** Контроль-хисап органы рәисеннән гайре.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында» 2008 елның 26 декабрендәге 135-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (V өлеш); 2011, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктның ундүртенче абзацында «контроль» сүзен «контроль-хисап» сүзенә алмаштырырга;

2) 12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«муниципаль районның, шәһәр округының контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы;»;

3) 14 пунктта:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:
«муниципаль районның, шәһәр округының контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы;»;
б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга;

4) 15 пунктта:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:
«муниципаль районның, шәһәр округының контроль-хисап органы аппараты инспекторы;»;
б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 51-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 969. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009 № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

а) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы составына хәлиткеч тавыш хокукы белән кергән очракта, муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлек уставын, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткәндә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»;

б) 6 өлештә «юстиция органнарында» сүзләрен «муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең теркәлгән уставын, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында теркәлгән муниципаль хокукый актны ул муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кергән көннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.»;

г) 8 өлешнең икенче абзацында «контроль» сүзен «контроль-хисап» сүзенә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 6 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге берләшмәләрне оештыру һәм аларның эшчәнлекләре «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль законның ассоциацияләргә карата кулланыла торган таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 13 статьяда:

а) «Муниципаль берәмлек» сүзләрен «1. Муниципаль берәмлек» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәртү тиешле муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелә торган халык фикерен исәпкә алып гамәлгә ашырылган очракларда, әлеге вәкиллекле органнар муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү турындагы мәсьәләнең киләчәктә каралачагы хакында халыкны алдан мәгълүмат белән тәэмин итәргә, шулай ук әлеге мәсьәлә буенча халыкка үз фикерен белдерү мөмкинлеген муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы уставы һәм (яисә) норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә тиеш. Бу чакта, әгәр муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы уставы яисә норматив хокукый акты белән мондый тәртип билгеләнмәгән булса, халык фикере гавами тыңлаулар уздыру юлы белән ачыклана. Бу очракта муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турындагы хәбәр, гавами тыңлаулар уздыру көненә 10 көннән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).»;

4) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19) җирлек территориясен төзекләндерүнең, шул исәптән биналарны (торак йортларын да кертеп), корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен карап тоту таләпләрен, тиешле биналар һәм корылмалар фасадларының һәм коймаларның тышкы кыяфәтенә карата таләпләрне билгели торган кагыйдәләрен, төзекләндерү эшләре исемлеген һәм аларны башкаруның эзлеклелеген раслау; биналар (алардагы урыннар) һәм корылмалар милекчеләренең шулар тирәсендәге территорияләрне

төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; җирлек территориясен (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары булган күрсәткечләрне урнаштыруны, кече архитектур формаларны урнаштыруны һәм карап тотуны да кертеп) төзекләндерүне, шулай ук шәһәр урманнарыннан, җирлек торак пунктлары чикләрендә урнашкан махсус сакланылучы табигать территорияләре урманнарыннан файдалануны, аларны саклауны, яклауны, торгызуны оештыру;»;

б) 20 пунктка «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карап чыгуларны гамәлгә ашыру һәм мондый карап чыгулар барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында рекомендацияләр бирү» сүзләрен өстәргә;

в) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21) урамнарга, мәйданнарга һәм торак пунктларында гражданнар яши торган бүтән территорияләргә исемнәр бирү, йортларның номерларын урнаштыру;»;

г) түбәндәге эчтәлекле 38 пункт өстәргә:

«38) җирлек чикләрендә коррупциягә каршы көрәш гамәлләрен тормышка ашыру.»;

5) $15^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый тикшереп торуны һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм итү.»;

6) 16 статьяда:

а) 1 өлештә:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) муниципаль район территориясендә (аерым территорияләр халкын медицина-санитария ягыннан тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы ведомствосындагы медицина учреждениеләрендә халкы медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән җирлекләр территорияләреннән гайре) Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру;»;

түбәндәге эчтәлекле 33 пункт өстәргә:

«33) муниципаль район чикләрендә коррупциягә каршы көрәш гамәлләрен тормышка ашыру.»;

б) 4 өлештә:

беренче абзацта «субвенцияләр исәбеннән» сүзләреннән соң «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «субвенцияләр исәбеннән» сүзләреннән соң «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча» сүзләрен өстәргә;

7) $16^1$ статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктны үз көчен югалткан дип таныргa;

б) түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9) кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый тикшереп торуны һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм итү.»;

8) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) шәһәр округы территориясендә (аерым территорияләр халкын медицина-санитария ягыннан тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы ведомствосындагы медицина учреждениеләрендә халкы медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән шәһәр округлары территорияләреннән гайре) Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру;»;

б) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25) шәһәр округы территориясен төзекләндерүнең, шул исәптән биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен карап тоту таләпләрен, тиешле биналар һәм корылмалар фасадларының һәм коймаларның тышкы кыяфәтенә карата таләпләрне билгели торган кагыйдәләрен, төзекләндерү эшләре исемлеген һәм аларны башкаруның ешлыгын билгеләүне (эзлеклелеген) раслау; биналар (алардагы урыннар) һәм корылмалар милекчеләренең шулар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; шәһәр округы территориясен (урамнарны яктыртуны, террито-

рияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары булган күрсәткечләрне урнаштыруны, кече архитектур формаларны урнаштыруны һәм карап тотуны да кертеп) төзекләндерүне, шулай ук шәһәр урманнарыннан, шәһәр округы чикләрендә урнашкан махсус сакланылучы табигать территорияләре урманнарыннан файдалануны, аларны саклауны, яклауны, торгызуны оештыру;»;

в) 26 пунктка «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карап чыгуларны гамәлгә ашыру һәм мондый карап чыгулар барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында рекомендацияләр бирү» сүзләрен өстәргә;

г) 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) урамнарга, мәйданнарга һәм шәһәр округында гражданнар яши торган бүтән территорияләргә исемнәр бирү, йортларның номерларын урнаштыру;»;

д) түбәндәге эчтәлекле 42 пункт өстәргә:

«42) шәһәр округы чикләрендә коррупциягә каршы көрәш гамәлләрен тормышка ашыру.»;

9) $17^1$ статьяның 1 өлешендә:

а) 8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый тикшереп торуны һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм итү.»;

10) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) 4 пунктта «күрсәтелүче хезмәтләргә» сүзләреннән соң «һәм муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган эшләргә» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^3$ пункт өстәргә:

«$4^3$) су белән тәэмин итү һәм су җибәреп тору өлкәсендә «Су белән тәэмин итү һәм су җибәреп тору турында» Федераль законда каралган вәкаләтләргә;»;

11) 21 статьяның 3 өлешендә «контроль» сүзен «контроль-хисап» сүзенә алмаштырырга;

12) 22 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның $2^1$ өлешендәге икенче абзацында каралган җирлектә җирлекнең сайлау хокукына ия халкы саны 100 кешедән арткан очракта, җирлекнең вәкиллекле органы сайлана. Җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары саны һәм аларның вәкаләтләре срогы халык тарафыннан гражданнар җыенында билгеләнә.

Татарстан Республикасы сайлау комиссиясе җирлекнең сайлау комиссиясен төзи, бу комиссия әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына сайлаулар билгели һәм сайлаулар уздыру буенча муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрен гамәлгә ашыра. Әлеге җирлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләре «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^2$ өлеш өстәргә:

«$2^2$. Әлеге статьяның $2^1$ өлешендә күрсәтелгән җыенны уздыру турында гражданнар инициативасы булмаган очракта:

1) җирлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатлары саны җиде кеше тәшкил итә;

2) җирлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатларының вәкаләтләре срогы биш ел тәшкил итә.»;

в) 8 өлешнең 6 пунктында «хезмәтләр күрсәтүгә» сүзләреннән соң «, эшләр башкаруга (федераль законнарда каралган очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

г) 11 өлештә «норматив характерга ия булмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 23 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы составына хәлиткеч тавыш хокукы белән кергән очракта, муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарларын кабул иткәндә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»;

14) 24 статьяда:

а) 3 өлешнең 1 пунктында «сайлана» сүзен «сайлана. Сайлау хокукына ия халкы саны 100 кешедән артмаган җирлектә муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен башкаручы гражданнар җыенында сайлана һәм җирле администрация башлыгы вәкаләтләрен башкара» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Муниципаль берәмлек башлыгы федераль законнар нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән үз компетенциясенә кертелгән бүтән мәсьәләләр буенча карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 11 өлеш өстәргә:

«11. Муниципаль берәмлек уставына муниципаль берәмлек башлыгын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан үз составыннан сайлауны күз алдында тота торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта, муниципаль берәмлек уставына әлеге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турындагы муниципаль норматив хокукый акт «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы муниципаль берәмлек башлыгын сайлаулар турында карар кабул итәргә хокуклы булган дата башланганчы үз көченә кергән булса, муниципаль берәмлек башлыгын сайлаулар билгеләнми һәм уздырылмый.»;

15) 26 статьяда:

а) 1 өлешнең дүртенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә вәкиллекле органы формалаша торган муниципаль районның җирле администрациясе башлыгы белән контракт муниципаль район уставында каралган срокка төзелә, әлеге срок ике елдан кимрәк, биш елдан артыграк була алмый.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Контракт буенча билгеләп куелучы җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатлар «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килергә тиеш. Муниципаль районның

(шәһәр округының) контракт буенча билгеләп куелучы җирле администрациясе башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә һәм муниципаль район (шәһәр округы) уставы белән дә билгеләнергә мөмкин. Җирлекнең контракт буенча билгеләп куелучы җирле администрациясе башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр җирлек уставы белән дә билгеләнергә мөмкин.»;

16) 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 статья. **Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы**

1. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан төзелә.

2. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органын оештыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыру һәм алар эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә. Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруны һәм аларның эшчәнлеген хокукый җайга салу шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән дә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш), № 12 (VI өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш); 2011, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 3 өлештә:

2 пунктта:

бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «Кече төркем» сүзләрен «Өлкән һәм кече төркемнәр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата:

Россия Федерациясе Конституциясен, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон), «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законны, Татарстан Республикасы Конституциясен, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, әлеге Законны, тиешле муниципаль берәмлек уставын, муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә карата башка норматив хокукый актларны, хезмәтне саклауның норматив таләпләрен һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, тиешле муниципаль органда эчке хезмәт тәртибен белү – барлык төркемнәр вазыйфалары өчен;

хезмәткә кагылышлы мәгълүмат белән эшләү, эшләр башкару һәм эшлекле аралашу нигезләре өлкәсендә белемнәр һәм күнекмәләр – югары, баш, әйдәүче һәм өлкән төркем вазыйфалары өчен.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль районның (шәһәр округының) контракт буенча билгеләнеп куела торган җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләп итеп кимендә биш ел идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсе булу билгеләнә. Әлеге өлештә идарә итү эшчәнлеге оешма, дәүләт органы, муниципаль орган җитәкчесе, җитәкче урынбасары вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында эшләүне аңлата. Контракт буенча билгеләнеп куела торган җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр муниципаль берәмлек уставы белән дә билгеләнергә мөмкин.»;

2) $8^2$ статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Билгеле бер төркемдәге муниципаль хезмәт вазыйфасына беренче мәртәбә билгеләнеп куела торган муниципаль хезмәткәрләргә 3 нче класслы чин бирелә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Федераль дәүләт граждан хезмәте классны чины, дипломатик рангы, хәрби яисә махсус дәрәҗәсе, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте классны чины, муниципаль хезмәтнең квалификация разряды булган граждан муниципаль хезмәткә урнашканда, аңа беренче классны чин муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме чикләрендә ул били торган вазыйфа нигезендә бирелә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Муниципаль хезмәткәргә әлеге статьяның $3^1$ өлеше нигезендә классны чин бирү максатларында, моңа кадәр билгеләнгән муниципаль хезмәтнең квалификация разрядлары һәм классны чиннары нисбәте, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте классны чиннары һәм федераль дәүләт граждан хезмәте, Россия Федерациясе башка субъектының дәүләт граждан хезмәте классны чиннары, шулай ук федераль дәүләт граждан хезмәте классны чиннары, дипломатик ранглар, хәрби һәм махсус дәрәҗәләр нисбәте кулланыла.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^3$ өлеш өстәргә:

«$3^3$. Әгәр, әлеге статьяның $3^2$ өлешендә каралган вазыйфаларның, классны чиннарның һәм квалификация разрядларының нисбәтләрен исәпкә алып, әлеге статьяның $3^1$ өлеше нигезендә бирелә торган муниципаль хезмәтнең классны чины муниципаль хезмәткәрнең федераль дәүләт граждан хезмәте классны чиныннан, дипломатик рангыннан, хәрби яисә махсус дәрәҗәсеннән, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте классны чиныннан, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядыннан түбәнрәк булса, муниципаль хезмәткәргә аның федераль дәүләт граждан хезмәте классны чиныннан, дипломатик рангыннан, хәрби яисә махсус дәрәҗәсеннән, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте классны чиныннан, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядыннан түбәнрәк булмаган, әмма ул били торган муниципаль хезмәт вазыйфасы караган муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме чикләрендә 1 нче класстан югарырак булмаган классны чин бирелә.»;

д) түбәндәге эчтәлекле $3^4$ өлеш өстәргә:

«$3^4$. Муниципаль хезмәткәргә чираттагы классны чин биргәндә федераль дәүләт граждан хезмәтенең тиешле классны чинында, дипломатик рангта, хәрби яисә махсус дәрәҗәдә, Та-

тарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте классы чинында, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядында булу дәвамлылыгы исәпкә алына.»;

е) 5 өлешнең беренче абзацында «өч ел» сүзләрен «бер ел» сүзләренә алмаштырырга;

ж) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

«$6^1$. Класслы чин бирү турында карар кабул ителгән көн класслы чин бирелгән көн дип санала. Класслы чин квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелгән очракта, класслы чин бирелгән көн муниципаль хезмәткәр квалификация имтиханы биргән көннән исәпләнә.»;

з) 8 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) класслы чиннар бирү эзлеклелеген сакламыйча муниципаль хезмәт вазыйфасының биләнүче вазыйфасына туры килә торган төркем чикләрендә бер дәрәҗәгә югарырак – 3 нче класслы чины булган муниципаль хезмәткәргә – 1 нче класслы чин, әмма ул тиешле класслы чинның 3 нче классында муниципаль хезмәт узу өчен әлеге статьяның 5 өлешендә билгеләнгән сроктан да алданрак була алмый.»;

и) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Аерым бер вәкаләтләр срогына муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә, югары төркем муниципаль хезмәт вазыйфаларына керә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрдән тыш, класслы чиннар квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелә. Квалификация имтиханы дәүләт граждан хезмәткәрләренә квалификация имтиханы тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.»;

к) 11 өлештә «муниципаль хезмәткәр хезмәт итә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе» сүзләрен «муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

л) 13 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турында карар, әлеге статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, бер айдан да соңга калмыйча түбәндәгечә кабул ителергә тиеш:

1) квалификация имтиханы үткәрелгән көннән;

2) класслы чин квалификация имтиханы үткәрелмичә генә бирелгәндә – барлык кирәкле документлар белән бергә, класслы чин бирү турында күрсәтмә класслы чиннар бирергә вәкаләтле

җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кертелгән көннән.»;

м) 14 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $8^3$ статья өстәргә:

«$8^3$ статья. **Муниципаль хезмәтнең класслы чинын саклап калу яисә аннан мәхрүм итү**

1. Муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм муниципаль хезмәттән җибәрелгәндә (шул исәптән пенсиягә чыкканда), шулай ук яңадан муниципаль хезмәткә урнашканда элек бирелгән класслы чин сакланып кала.

2. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләп куйганда, аның элек бирелгән класслы чины билгеләнгән тәртиптә чираттагы класслы чин бирелгәнче сакланып кала.

3. Бирелгән класслы чиннан мәхрүм итү федераль законнар нигезендә суд карары белән башкарылырга мөмкин.»;

4) 11 статьяның 1 өлешендә:

а) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) билгеләнгән тәртиптә үзе һәм үзенең гаилә әгъзалары турында федераль законнарда каралган белешмәләрне тапшырырга;»;

б) 11 пунктта «яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итәргә» сүзләрен «үзенең турыдан-туры җитәкчесенә язма рәвештә хәбәр итәргә» сүзләренә алмаштырырга;

5) $11^1$ статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль хезмәткәрнең шәхси кызыксынучанлыгы» сүзләрен «муниципаль хезмәткәрнең шәхси кызыксынучанлыгы (турыдан-туры яисә өлешчә)» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу мәнфәгатьләр конфликтында катнашучы муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи яисә хезмәттәге хәлен үзгәртүгә, хәтта билгеләнгән тәртиптә аны вазыйфаи (хезмәт) бурычларын үтәүдән тулысынча читләштерүгә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгуга сәбәп булган файданы алудан баш тарттыруга китерергә мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^2$ өлеш өстәргә:

«$2^2$. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затның кыйммәтле кәгазьләргә, акцияләргә (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләренә, пайларына) ия булуы мәнфәгатьләр конфликтына китерсә яисә китерергә мөмкин булса, шушы зат үзенә караган кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларын) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга тиеш.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $2^3$ өлеш өстәргә:

«$2^3$. Мәнфәгатьләр конфликтында катнашучы муниципаль хезмәткәр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә аны җайга салу чаралары күрелмәү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.»;

д) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында мәгълүм булган яллаучының вәкиле булып торучы муниципаль хезмәткәр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу чаралары күрелмәү яллаучы вәкиле булып торучы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.»;

е) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенең гомуми принциплары үтәлүен һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салуны тәэмин итү өчен җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый акт белән билгеләнә торган тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу комиссияләре төзелергә мөмкин.»;

6) 12 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, шушы вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) ел саен үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының

(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш. Бу белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә һәм рәвештә тапшырыла.»;

б) 3 өлештә «Муниципаль хезмәткәрнең түләү мөмкинлеген урнаштыру яисә билгеләү өчен» сүзләрен «Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының түләү сәләтен билгеләү һәм ачыклау өчен» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан, үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булып та, аларны тапшырмау йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткә урнашканда Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрнең муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үтәлүен, аларның «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән үз бурычларының үтәлүен тикшерү Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләргә, мон-

дый гражданнарның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хатыннарына (ирләренә) һәм балигъ булмаган балаларына карата банк, салым серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләр тапшыру турындагы гарызнамәләр, оператив-эзләнү чараларын башкару турында хокук саклау органнарына гарызнамәләр муниципаль органнар мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә җибәрелә.»;

7) 13 статьяның 7 өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон)» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

8) 19 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәтнең югары һәм баш вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә ел саен бирелә торган түләүле төп отпуск 35 календарь көн озынлыгында бирелә. Муниципаль хезмәтнең башка төркемнәр вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә ел саен бирелә торган түләүле төп отпуск 30 календарь көн озынлыгында бирелә.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпусклар тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда һәм әлеге Законда каралган очракларда бирелә. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпускның озынлыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән чыгып санала. Ел саен бирелә торган түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпускның гомуми озынлыгы 45 календарь көннән артмаска тиеш. Нормалаштырылмаган эш көне өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпуск, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда ел саен бирелә торган түләүле өстәмә отпусклар ел саен бирелә торган түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен ел саен бирелә торган түләүле өстәмә

отпускның әлеге өлештә каралган гомуми көннәргә өстәп бирелә.»;

9) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 26[1] статья өстәргә.

«26[1] статья. **Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җәзалар**

1. Муниципаль хезмәткәр чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен әлеге Законның 26 статьясында каралган җәзалар билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәр, әлеге Законның 11[1] һәм 12 статьяларында каралган хокук бозуларны кылган очракларда ышанычын югалтуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәттән җибәрелергә тиеш.

3. Әлеге Законның 11[1], 12 һәм 26 статьяларында каралган җәза чаралары яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә кулланыла:

1) тиешле муниципаль органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе (алга таба – хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе) тарафыннан уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турындагы нотык;

2) әгәр тикшерү нәтиҗәләре турындагы нотык муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә җибәрелсә, комиссия күрсәтмәсе;

3) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары;

4) башка материаллар.

4. Хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан тикшерү уздыру өчен түбәндәгеләр тарафыннан җитәрлек итеп язма рәвештә бирелгән мәгълүмат нигез була:

1) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

2) сәяси партияләрнең региональ яисә җирле бүлекчәләре, шулай ук закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган региональ иҗтимагый берләшмәләр;

3) тиешле муниципаль берәмлектә төзелгән иҗтимагый совет;

4) массакүләм мәгълүмат чаралары.

5. Аноним хәбәрләр хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

6. Тикшерү уздырганчы хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе муниципаль хезмәткәрдән язма рәвештә аңлатма алырга тиеш. Әгәр ике эш көне эчендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге аңлатма бирелмәсә, тиешле акт төзелә. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан аңлатма бирелмәү тикшерү уздыруга тоткарлык була алмый.

7. Әлеге Законның $11^1$ статьясындагы $2^3$ яисә $3^1$ өлешендә каралган хокук бозуларны муниципаль хезмәткәр кылган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында нотык, муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә җибәрелә, ул яллаучы вәкил (эш бирүче) өчен муниципаль хезмәткәргә дисциплинар җәза куллану буенча күрсәтмәләр әзерли.

Муниципаль хезмәткәр башка төрле хокук бозган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында нотык, муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла.

8. Әлеге Законның $11^1$, 12 һәм 26 статьяларында каралган җәза чараларын кулланганда, муниципаль хезмәткәр кылган коррупциячел хокук бозуның характеры, аның авырлыгы, аны кылгандагы шартлар, башка чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрнең муниципаль хезмәткәр тарафыннан үтәлүе һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларның үтәлүе, шулай ук моңа кадәр муниципаль хезмәткәрнең үз вазыйфаи бурычларын башкару нәтиҗәләре исәпкә алына.

9. Әлеге Законның 11[1], 12 һәм 26 статьяларында каралган җәза чаралары муниципаль хезмәткәрнең коррупциячел хокук бозуы ачыкланган көннән бер айдан да соңга калмыйча кулланыла, бу вакытка муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булган чоры, ул отпускта булган чор, мөһим сәбәпләр аркасында хезмәттә булмаган башка очраклар чоры, шулай ук хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан уздырылган тикшерү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе тарафыннан әлеге тикшерү материалларын карау вакыты керми. Шул ук вакытта җәза бирү коррупциячел хокук бозу башкарылган көннән алты айдан да соңга калмыйча кулланылырга тиеш.

10. Муниципаль хезмәткәр коррупциячел хокук бозган очракта, аңа карата җәза куллану турындагы актта җәза куллану нигезе буларак «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 27[1] статьясындагы 1 яисә 2 өлеш күрсәтелә.

11. Муниципаль хезмәткәргә карата җәза куллану турындагы актның күчермәсе, хокук бозуны һәм нигезләмәләре бозылган норматив хокукый актларны күрсәтеп, яисә муниципаль хезмәткәргә карата мондый җәза кулланудан баш тарту турындагы актның күчермәсе, дәлилләрен күрсәтеп, тиешле акт чыгарылган көннән өч эш көне эчендә муниципаль хезмәткәргә расписка белән тапшырыла. Әгәр муниципаль хезмәткәр күрсәтелгән расписканы бирүдән баш тартса, тиешле акт төзелә.

12. Җәзага карата муниципаль хезмәткәр тарафыннан федераль закон нигезендә шикаять бирелергә мөмкин.

13. Әгәр җәза кулланган көннән бер ел эчендә муниципаль хезмәткәр әлеге Законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 1 яисә 2 пунктында каралган дисциплинар җәзага тартылмаса, аның җәзасы юк дип санала.

14. Яллаучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрдән әлеге Законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 1 яисә 2 пунктында каралган дисциплинар җәзаны, ул бирелгән көннән бер ел узганчы, үз инициативасы, муниципаль хезмәткәрнең язма гаризасы яисә аның турыдан-туры җитәкчесе үтенече буенча кире алырга хокуклы.»;

10) 36 статьяда:

а) 1 өлештә «, 34 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләреннән» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Законның 22 статьясы 2009 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, һәм аның гамәли көче 2006 елның 1 гыйнварыннан муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затларга кагыла.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 4 пунктының «б» пунктчасыннан, 8 пунктының «в» пунктчасыннан һәм 10 пунктының «б» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «б» пунктчасы, 8 пунктының «в» пунктчасы һәм 10 пунктының «б» пунктчасы 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 52-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 970. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; Ватаным Татарстан, 2012, 17 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

«Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр федераль законнардагы мәгънәләрендә кулланыла.»;

2) 6 статьяда:

а) алтынчы абзацта «кишәрлекләрен Россия Федерациясе белән берлектә бүлеп бирү» сүзләрен «кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү» сүзләренә алмаштырырга;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен билгеләү;»;

в) сигезенче абзацта «үз ихтыяҗлары» сүзләрен «үзләренең җитештерү һәм технология ихтыяҗлары» сүзләренә алмаштырырга, «тау токымнары» сүзләреннән соң «һәм (яисә) геологик токымнар» сүзләрен өстәргә;

г) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү тәртибен билгеләү;»;

3) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

файдалы казылмаларның разведкаланган запаслары турындагы һәм җир асты байлыкларының кыйммәтен яисә хәвефлелеген билгели торган башка үзенчәлекләре турындагы мәгълүматка дәүләт экспертизасында катнашу;

республика геологик мәгълүмат фондларын төзү һәм алып бару, Татарстан Республикасы бюджеты һәм тиешле җирле бюджетлар акчалары исәбенә алынган мәгълүмат белән эш итү;

җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе федераль органы яисә аның территориаль органнары белән килештереп, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлекләрен әзерләү һәм раслау;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары һәм чагылышлары запасларының республика балансларын һәм кадастрларын төзү һәм файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләрен исәпкә алу;

файдалы казылмалар запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрү;

җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турындагы гарызнамәләрне карау өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе федераль органы тарафыннан төзелә торган комиссия эшендә катнашу;

Татарстан Республикасы законнары нигезендә түбәндәгеләр турында карарлар кабул итү:

җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан расланган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару яисә гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү турында;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасы булган һәм җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан расланган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык ятманың гомумтаралган файдалы казылмаларын разведкалау һәм чыгару өчен, мондый җир асты байлыклары кишәрлеген гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү эшләрен башкарган, әлеге эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан аның ачылу факты билгеләнгәндә, файдалану хокукын бирү турында;

файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану хокукын бирү турында;

җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан расланган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән гомумтаралган файдалы ка-

зылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында аны геологик өйрәнү өчен файдалану хокукын бирү турында;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануны лицензияләүнең дәүләт системасы эшчәнлеген тәэмин итү;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану шартларын әзерләү;

җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануны лицензияләү программасын төзү, конкурслар һәм аукционнар үткәрү шартлары һәм лицензияләр шартлары буенча тәкъдимнәрне җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе федераль органына яисә аның территориаль органнарына тапшыру;

федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирүгә конкурслар һәм аукционнар үткәргәндә җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе федераль органы яисә аның территориаль органнары тарафыннан төзелә торган конкурслар һәм аукционнар комиссияләре составында катнашу;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

4) 9 статьяда:

а) дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) бишенче абзацта «(1995 елның 3 мартындагы 27-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 16 статьяда:

а) унберенче – ундүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан расланган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару яисә гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү турында;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм

эксплуатацияләү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасы булган һәм җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан расланган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык ятманың гомумтаралган файдалы казылмаларын разведкалау һәм чыгару өчен, мондый җир асты байлыклары кишәрлеген гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү эшләрен башкарган, әлеге эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан аның ачылу факты билгеләнгәндә, файдалану хокукын бирү турында;

файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану хокукын бирү турында;»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан расланган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында аны геологик өйрәнү өчен файдалану хокукын бирү турында.»;

6) түбәндәге эчтәлекле III[1] бүлек өстәргә:

«III[1] БҮЛЕК
## ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ҖИР АСТЫ БАЙЛЫКЛАРЫ КИШӘРЛЕКЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ ХОКУКЫН БИРҮ

35[1] статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү**

Гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы, әлеге статьяның икенче өлешендәге өченче һәм дүртенче абзац-

ларында каралган очраклардан тыш, аукцион нәтиҗәләре буенча бирелә.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы түбәндәге максатлар өчен аукцион үткәрмичә генә бирелә:

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү;

ачык ятманың гомумтаралган файдалы казылмаларын разведкалау һәм чыгару, мондый җир асты байлыклары кишәрлеген гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү эшләрен башкарган, әлеге эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан аның ачылу факты билгеләнгәндә;

файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

$35^2$ статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү тәртибе**

Әлеге Законның $35^1$ статьясындагы беренче өлешендә күрсәтелгән максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга аукционда катнашу өчен шул аукционда катнашуга дәгъва кылучы (әлеге статьяда алга таба – мөрәҗәгать итүче) җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвеш буенча гариза бирә, шулай ук түбәндәге документларны тапшыра:

мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документларының күчермәләрен (әгәр мөрәҗәгать итүче юридик зат булса);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтәне;

мөрәҗәгать итүчене салым органында, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп, исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычы булу яисә булмау турында салым органнарыннан белешмәне;

мөрәҗәгать итүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсен;

мөрәҗәгать итүченең аукционда катнашуга гариза бирелгән датага кадәрге ай эчендә счетлар буенча акчаларының йөреше турында банк учреждениеләреннән белешмәләрне;

заем яисә кредит шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

подряд шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

кулланыла торган технологияләр турында, аларның тасвирламалары белән, белешмәне һәм бораулау, тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чараларның, аларның мөрәҗәгать итүчегә йә җәлеп ителүче подрядчикка каравын раслый торган документлар белән, исемлеген;

мөрәҗәгать итүченең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә җәлеп ителүче подрядчикларның лицензияләре (алар булса) күчермәләрен;

мөрәҗәгать итүченең йә җәлеп ителүче подрядчикларның штат расписаниесе күчермәсен;

эшләр башкарачак квалификацияле белгечләрнең дипломнары күчермәләрен.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга йә төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү турында, аукцион комиссиясенең составы һәм эш тәртибе турында карарлар кабул итү һәм һәр җир асты байлыгы кишәрлегенә яисә җир асты байлыклары кишәрлекләре төркеменә карата мондый аукционнарны үткәрү тәртибен һәм шартларын билгеләү җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

35[3] статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә генә бирү тәртибе**

Әлеге Законның 35[1] статьясындагы икенче өлешендә күрсәтелгән максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен әлеге хокукны алуга дәгъва кылучы (әлеге статьяда – мөрәҗәгать итүче) җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвеш буенча гариза бирә.

Мөрәҗәгать итүчегә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карар кабул итү өчен әлеге Законның 35[2] статьясында каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

гариза бирелгән вакытка җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма язуы;

гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын раслау беркетмәсенең күчермәсе (әлеге Законның 35[1] статьясындагы икенче өлешенең өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән максатлар өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын биргәндә);

җир асты корылмасын төзүнең расланган проектыннан төзелеш объекты күләмнәре турындагы белешмәләр булган өземтә (әлеге Законның 35[1] статьясындагы икенче өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән максатлар өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын биргәндә);

гариза бирүче гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен файдалана торган эчке елга һәм катнаш («елга-диңгез») йөзү судноларын «ГЛОНАСС» яисә «ГЛОНАСС/GPS» спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җайланма урнаштыру акты күчермәсе (гариза бирүче күрсәтелгән суднолардан файдаланганда);

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү турындагы таны-

лык күчермәсе (әлеге Законның $35^{1}$ статьясындагы икенче өлешенең өченче абзацында күрсәтелгән максатлар өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын биргәндә).

Әлеге Законның $35^{2}$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның икенче өлешендәге икенче – алтынчы абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче гариза биргән вакытта тапшырыла. Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга йә төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Әлеге Законның $35^{2}$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында, шулай ук әлеге статьяның икенче өлешендәге җиденче абзацында караган документлар, әгәр әлеге документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы мөстәкыйль соратып ала.

Гариза һәм барлык кирәкле документлар алынган көннән башлап 20 эш көненнән дә соңга калмыйча җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын мөрәҗәгать итүчегә бирү турында яисә мондый хокукны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, тиешле карар кабул ителгән вакыттан өч эш көне эчендә бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә. Шул ук вакытта лицензия бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә, баш тартуның сәбәбе күрсәтелеп, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә җибәрелә (тапшырыла).

$35^{4}$ статья. **Аукционда катнашуга гаризаны йә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә генә алуга гаризаны кабул итүдән баш тарту**

Аукционда катнашуга гаризаны йә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә генә алуга гаризаны кабул итүдән баш тарту түбәндәге очракларда булырга мөмкин:

гариза билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән булса, шул исәптән аның эчтәлеге аукционның игълан ителгән шартларына туры килмәсә;

мөрәҗәгать итүче белә торып үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырган булса;

мөрәҗәгать итүче эшләрне нәтиҗәле һәм имин алып бару өчен үзендә квалификацияле белгечләрнең, кирәкле финанс һәм техник чараларының булуы яисә булачагы турында дәлилләрне тапшырмаган яисә тапшыра алмый торган булса;

шушы мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта, монополиягә каршы законнар таләпләре үтәлми торган булса.»;

7) түбәндәге эчтәлекле 83[1] статья өстәргә:

«83[1] статья. **Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү**

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләүне җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан төзелә һәм составына җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе федераль органы яисә аның территориаль органнары вәкилләре керә торган комиссия башкара.».

**2 статья**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән яисә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатлар өчен файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын алу тәртибен раслау турында» 2003 елның 15 декабрендәге 2459 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (III өлеш); 2010, № 3);

2) «Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән яисә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатлар өчен файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын алу тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 10 июлендәге 4012-III ДС номерлы Татарстан Рес-

публикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 7 (III өлеш);

3) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2003 елның 15 декабрендәге 2459 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән яисә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатлар өчен файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын алу тәртибенә 2 нче кушымтаның 3 һәм 6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип тану турында» 2010 елның 12 мартындагы 773-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 3).

**3 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статьяның 2 өлешеннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 30 көн узгач, ә ул өлеш шушы Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән дә соңга калмыйча үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 53-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 971. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1) 16 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләр чоры чикләрендә гамәлдә була һәм яңа сайланган Татарстан Республикасы Президенты алдында үз вәкаләтләрен туктата. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының үз вәкаләтләрен туктатуы турындагы карар Татарстан Республикасы Президенты үз вазыйфасына керешкән көндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә.»;

2) 18 статьяның 2 пунктында «вәкаләтләр яңа бирелгән» сүзләрен «сайланган» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1-2, № 4 (I өлеш); № 12; 2011, № 5) «вәкаләтләр бирү,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында» 1991 елның 4 июлендәге 1141-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 3; 2005, № 6 (I өлеш); 2010, № 3);

2) «Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында» 2004 елның 25 мартындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (IV өлеш);

3) «Сайлаулар һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм «Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2005 елның 31 мартындагы 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 3 (I өлеш); 2007, № 5);

4) «Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында» Татарстан Республикасы Законындагы 1 статьяның гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2005 елның 15 июнендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 6 (I өлеш).

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 54-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 972. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законны җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе буенча түләүләрнең очракларын, тәртибен һәм күләмнәрен билгели.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт тарафыннан мәҗбүри иминләштерелергә тиешле дәүләт хезмәткәрләренә кагылмый.

2 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Граждан хезмәткәрләренең гомере һәм сәламәтлеге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен (алга таба – граждан хезмәте) узуның граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнеп куелу көненнән алып граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителү көненә кадәр исәпләнә торган бөтен чоры дәвамында дәүләт тарафыннан мәҗбүри иминләштерелергә тиеш.

2. Әлеге Законның 4 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында каралган иминият очраклары барлыкка килгәндә, иминият түләвен алу хокукы, әгәр граждан хезмәткәренең вафаты яки инвалидлык алуы граждан хезмәтен узган чорда имгәнү, травма алу яисә авыру аркасында булса, граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында саклана.

3. Иминиятчене сайлап алу дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Граждан хезмәткәрләре граждан хезмәтен уза торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары мәҗбүри дәүләт иминләштерүе буенча иминләштерүчеләр (алга таба – иминләштерүчеләр) булып торалар.

5. Граждан хезмәткәрләре мәҗбүри дәүләт иминләштерүе буенча иминләштерелгән затлар (алга таба – иминләштерелгән затлар) булып торалар.

3 статья. **Мәҗбүри дәүләт иминияте шартнамәсе**

1. Мәҗбүри дәүләт иминияте шартнамәсе (алга таба – иминият шартнамәсе) иминләштерүче һәм иминиятче арасында иминләштерелгән зат (файда алучы) файдасына Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә тәүлекнең 24 сәгате дәвамында иминият яклавы белән бер календарь елга төзелә.

2. Иминләштерүче иминият шартнамәсендә әлеге Законның 4 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән иминият очраклары өчен файда күрүчеләрнең даирәсен билгели. Иминият шартнамәсендә файда күрүчеләр буларак иминләштерүче тарафыннан түбәндәгеләр мәҗбүри рәвештә аталырга тиеш: иминләштерелгән зат вафат булган көнгә аның рәсми никахта торучы ире (хатыны); иминләштерелгән затның ата-анасы (аны уллыкка алучылар); иминләштерелгән затның ата-анасы булмаса, аны кимендә өч ел тәрбияләгән яки тәэмин итеп торган бабасы һәм әбисе; иминләштерелгән затның аны кимендә биш ел тәрбияләгән яки тәэмин итеп торган үги әтисе һәм үги әнисе; иминләштерелгән затның 18 яшькә җитмәгән яисә 18 яшенә җиткәнче инвалид булган өлкәнрәк яшьтәге балалары, шулай ук теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милек рәвешендәге белем бирү учреждениесендә белем алу-

чы балалары – укуы тәмамланганчы, әмма 23 яшенә җиткәнче; иминләштерелгән затның опекага алынган затлары. Файда күрүчеләр иминият шартнамәсендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан аны иминләштерүче билгеләгән тәртиптә бирелә торган мәгълүмат нигезендә күрсәтелә. Файда күрүчеләр иминият шартнамәсендә күрсәтелмәгән очракта, иминләштерелгән затның граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән варислары файда күрүчеләр булып таныла.

3. Граждан хезмәткәрен граждан хезмәте вазыйфасыннан төзелгән иминият шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланганчыга кадәр азат итү күрсәтелгән граждан хезмәткәренә карата иминият шартнамәсенең гамәлдә булуын граждан хезмәте вазыйфасыннан азат итү датасыннан туктатуга китерә. Күрсәтелгән нигез буенча граждан хезмәткәренә карата иминият шартнамәсенең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, иминиятче иминләштерүчегә әлеге граждан хезмәткәрен иминләштерүгә бәйле рәвештә иминият премиясен шушы дәүләт хезмәткәренә карата иминият шартнамәсенең калган гамәлдә булу чорына пропорциональ өлешендә әлеге Законның 8 статьясында билгеләнгән тәртиптә кире кайтарып бирә.

4 статья. **Иминият очраклары**

Иминият очраклары түбәндәгеләр:

1) иминләштерелгән затның граждан хезмәтен узган чорда, шулай ук граждан хезмәтен узган чорда имгәнү, травма алу яки авыру сәбәпле граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында вафат булуы;

2) иминләштерелгән затка граждан хезмәтен узган чорда, шулай ук граждан хезмәтен узган чорда имгәнү, травма алу яки авыру сәбәпле граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында инвалидлык билгеләнү;

3) иминләштерелгән затның граждан хезмәтен узган чорда имгәнүе яки травма алуы;

4) иминләштерелгән затның, яллаучы вәкиле инициативасы белән медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча граждан хезмәткәрен били торган граждан хезмәте вазыйфасыннан азат итеп, граждан хезмәтеннән җибәреп, хезмәт контрактын өзү өчен нигез булып торган һәм инвалидлык билгеләнүгә бәйле булмаган авыру алуы.

5 статья. **Иминият суммаларының һәм иминият премияләренең күләмнәре**

1. Иминләштерелгән затларга (файда күрүчеләргә) түләнә торган иминият суммаларының күләмнәре граждан хезмәткәренең үзе били торган граждан хезмәте вазыйфасы нигезендә айлык окладыннан һәм граждан хезмәткәренең үзенә бирелгән граждан хезмәте класслы чины нигезендә айлык окладыннан гыйбарәт булган граждан хезмәткәренең айлык акчалата кереме окладыннан (алга таба – оклад) чыгып билгеләнә.

2. Иминият суммасын исәпләгәндә граждан хезмәткәренең иминият очрагы барлыкка килгән көнгә билгеләнгән окладына, аның артуын (индексациясен) да кертеп, исәпкә алына.

3. Иминият очраклары барлыкка килгәндә, иминият суммалары түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

1) иминләштерелгән зат граждан хезмәтен узган чорда, шулай ук граждан хезмәтен узган чорда имгәнү, травма алу яки авыру сәбәпле граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында вафат булган очракта – 75 оклад. Күрсәтелгән иминият суммасы файда күрүчеләргә бертигез өлешләрдә түләнә;

2) иминләштерелгән затка граждан хезмәтен узган чорда, шулай ук граждан хезмәтен узган чорда имгәнү, травма алу яки авыру сәбәпле граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында инвалидлык билгеләнгән очракта:

I төркем инвалидына – 50 оклад;

II төркем инвалидына – 35 оклад;

III төркем инвалидына – 30 оклад;

3) иминләштерелгән зат граждан хезмәтен узган чорда авыр имгәнү яисә травма алган очракта – 20 оклад, җиңелчә имгәнгән яисә травма алган очракта – биш оклад түләнә. Тиешле иминият суммасы түләнә торган имгәнүләрне һәм травмаларны авыр яисә җиңелчә төргә кертү «Хәрби хезмәткәрләр, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарының гади һәм башлык составы затлары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хезмәткәрләре гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 1998 елның 28 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән, авыр яисә җиңелчә төргә кертелгән имгәнүләр (яраланулар, травмалар, контузияләр) исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла;

4) иминләштерелгән затның, яллаучы вәкиле инициативасы белән медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча граждан хезмәткәрен били торган граждан хезмәте вазыйфасыннан азат итеп, граждан хезмәтеннән җибәреп, хезмәт контрактын өзү өчен нигез булып торган һәм инвалидлык билгеләнүгә бәйле булмаган авыру алган очрагында – 25 оклад.

4. Граждан хезмәтен узган чорда йә граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел узганчыга кадәр медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениедә кабат таныклау узган вакытта иминләштерелгән затка инвалидлык төркеме күтәрелсә, иминият суммасы күләме яңа билгеләнгән инвалидлык төркеме буенча окладлар саны белән элеккеге инвалидлык төркеме буенча тиеш булган окладлар саны аермасы тәшкил иткән суммага арттырыла.

5. Әгәр иминләштерелгән затка иминият очрагына бәйле иминият суммасы түләнгән булса, әмма иминият очрагы кергән көннән алып ел дәвамында һәм шуңа турыдан-туры бәйле рәвештә аның сәламәтлеге какшаса яки ул вафат булса, элек түләнгән иминият суммасын (иминият суммаларын) чигереп, өстәмә иминият түләве башкарыла.

6. Һәр иминләштерелгән зат өчен түләнә торган иминият премиясенең күләме иминият шартнамәсе белән билгеләнә һәм иминләштерелгән затның иминият шартнамәсен төзү вакытына билгеләнгән окладының 25 процентыннан арта алмый.

6 статья. **Иминиятчене иминият суммасын түләүдән азат итү нигезләре**

1. Иминиятче мәҗбүри дәүләт иминләштерүе буенча иминият суммасын түләүдән азат ителә, әгәр иминият очрагы:

1) иминләштерелгән затның суд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый куркыныч дип танылган гамәл кылуы аркасында булса;

2) иминләштерелгән затның алкоголь, наркотик яки агулы матдәләр белән исерүенә турыдан-туры бәйле булса, һәм ул суд тарафыннан расланса;

3) иминләштерелгән затның үз сәламәтлегенә белә торып зыян китерүе яки иминләштерелгән затның үзенә кул салуы аркасында булса, һәм ул суд тарафыннан расланса.

2. Иминләштерелгән затның вафат булуы үзенә кул салу аркасында булып, суд тарафыннан расланса, иминиятче иминият суммасын түләүдән азат ителми.

3. Иминият суммасын түләүдән баш тарту турында карар иминиятче тарафыннан кабул ителә һәм иминләштерелгән затка (файда күрүчегә) һәм иминләштерүчегә, күрсәтелгән баш тарту сәбәпләрен мәҗбүри рәвештә дәлилле нигезләп, иминият суммасын түләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вакыт эчендә язмача хәбәр ителә.

7 статья. **Иминият суммаларын түләү тәртибе һәм шартлары**

1. Иминият түләүләре иминләштерелгән затның (файда күрүченең) гаризасы һәм иминләштерүче тарафыннан тапшырылган, иминият очрагы барлыкка килүне раслый торган документлар нигезендә иминиятче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Иминият түләвен гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документларның исемлеге, аларны тапшыру һәм карау тәртибе иминият шартнамәсе белән билгеләнә.

3. Иминият суммалары иминләштерелгән затларга башка төрле иминият шартнамәләре буенча тиешле суммаларга бәйсез рәвештә түләнә.

4. Иминиятче тарафыннан иминият суммалары иминләштерелгән затларга (файда күрүчеләргә) рубльләрдә түләнергә тиешле суммаларны иминият шартнамәсендә билгеләнгән ысул белән күчереп түләнә.

5. Иминият суммаларын түләү күрсәтелгән түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар алынган көннән алып 10 көн эчендә башкарыла.

8 статья. **Иминләштерүче һәм иминиятченең үзара исәп-хисап ясау тәртибе**

1. Иминият шартнамәсенең гамәлдә булу чоры дәвамында иминләштерелгән затларның окладлары күләмнәре, шулай ук аларның саны үзгәрсә, күрсәтелгән хәлләргә бәйле рәвештә алынып бетмәгән яки артык алынган иминият кертемнәре суммалары өстәмә түләнергә яисә кире кайтарылырга тиеш. Иминият шартнамәсен төзегән яклар килешүе буенча күрсәтелгән суммалар иминият шартнамәсенең чираттагы гамәлдә булу чорында иминият кертемнәре күләмнәрен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

2. Иминият кертемнәрен иминләштерүче тарафыннан кертүнең дәвамлылыгы иминият шартнамәсе белән билгеләнә.

9 статья. **Мәҗбүри дәүләт иминләштерүенә чыгымнарны финанслау**

Мәҗбүри дәүләт иминләштерүенә чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджетының бу максатларга каралган акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, моңа әлеге Законның рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә торган 2 статьясының 3 өлеше һәм әлеге статьясының 2 өлеше керми.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 55-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 973. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш); 2007, № 10; 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) 2 пунктны көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, бүтән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, шулай ук Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чараларында сүз ирегe саклануга иҗтимагый контрольлек итүне гамәлгә ашыру.»;

2) 15 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Иҗтимагый палата рәисен сайлау һәм вазыйфасыннан азат итү тәртибе, аның вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе;

5) Иҗтимагый палата рәисе урынбасарларын сайлау һәм вазыйфаларыннан азат итү тәртибе, аларның вәкаләтләре, саны һәм эшчәнлек тәртибе;»;

3) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ статья өстәргә:

«$16^1$ статья. **Иҗтимагый палата рәисе, аның урынбасарлары**

1. Иҗтимагый палата рәисе вазыйфасы буенча Иҗтимагый палата Советын җитәкли, Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата Советы, Иҗтимагый палатаның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыра, Иҗтимагый палата һәм Иҗтимагый палата Советы утырышларында рәислек итә, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында, башка органнарда һәм оешмаларда Иҗтимагый палата исеменнән эш йөртә.

2. Иҗтимагый палата рәисе Иҗтимагый палата утырышында сайлана.

3. Иҗтимагый палата рәисе урынбасарлары Иҗтимагый палата рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый палата утырышында Иҗтимагый палата әгъзалары арасыннан сайланып куелалар һәм вазыйфаларыннан азат ителәләр.»;

4) 17 статьядагы 3 –5 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 56-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 974. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлектә:

а) өченче абзацта «аның» сүзеннән соң «инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген һәм» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа егерме өченче абзац өстәргә:

«Санап кителгән институциональ факторларның һәрберсен анализлаганда функциональ блокларның ачыкланууын билгеләп үтәргә кирәк, аларның бергәлеге, тулаем алганда, эшлекле активлыкның, инвестиция җәлеп итүчәнлекнең, икътисад һәм социаль өлкәдәге барлык секторларны инновацияле модернизацияләүнең үсеш дәрәҗәсен һәм шул нигездә аларның конкуренциягә сәләтлелеге артуын характерлый.»;

в) егерме өченче – утыз өченче абзацларны тәңгәл рәвештә егерме дүртенче – утыз дүртенче абзацлар дип санарга;

2) 3 бүлектә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Куелган бурычларны хәл итү юлларын нигезле сайлап алу һәм шуның нигезендә Программа максатларына ирешү өчен Татарстан Республикасының икътисад тармакларындагы вәзгыять үсешен 1 бүлектә санап кителгән институциональ факторларның инновация һәм инвестиция эшчәнлеген алга таба үстерү стратегиясенә йогынты ясавы күзлегеннән чыгып карарга кирәк. Моннан тыш, әлеге бурычларны хәл итү өчен сайлап алынган юллар республиканың инвестиция стратегиясен барлыкка китерәләр. Бу тезисның аеруча актуаль булуы Татарстан Республикасын Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимия-

те органнарының уңай инвестиция климатын тәэмин итү буенча эшчәнлеге стандартын апробацияләүдә катнашучы Россия Федерациясе субъектлары исәбенә кертү белән билгеләнә.»;

б) икенче абзацта «бу» сүзен «югарыда санап кителгән» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3.1 бүлекчәдә:

3.1.2 пунктта:

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«– Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы, ул экология кагыйдәләренең һәм нормаларының үтәлеше, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе өчен җаваплы;»;

егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«– Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, ул энергия челтәре хуҗалыгына һәм нефть-газ химиясе комплексына идарә итүгә җаваплы;»;

3.1.3 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын булдыру һәм алып бару тәртибен регламентлаштыра торган норматив хокукый акт проектын эшләргә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2012 ел»; |

6 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктчада «2011 ел» сүзләрен «2012 ел» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «8. Федераль законнарга өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен төзелеш алып баручыларның җаваплылыгын арттыруга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр эшләргә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2012 ел»; |

11 пунктчада «Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктчада «2011 елның 1 нче яртыеллыгы» сүзләрен «2012 ел» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «15. Махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләре турындагы белешмәләрне дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрына кертергә | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | 2011 – 2015 еллар»; |

г) 3.2 бүлекчәнең 3.2.3 пунктында:

5 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «8. Инвестиция проектларын «бер тәрәзә» принцибы буенча йөртүнең бердәм регламентын билгели торган норматив хокукый акт проектын эшләргә | Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2012 ел»; |

түбәндәге эчтәлекле 14 – 16 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «14. Татарстан Республикасының инвестиция декларациясен раслау турында норматив хокукый акт проектын эшләргә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы | 2012 – 2013 еллар |
| 15. Инвестиция объектларын һәм инфраструктура объектларын төзү планын булдыру механизмын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга | Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2012 – 2015 еллар |
| 16. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының республикада уңай инвестиция климатын тәэмин итү буенча эшчәнлек стандартын гамәлгә ашырырга | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы, тармак министрлыклары | 2012 ел»; |

д) 3.4 бүлекчәдә:

3.4.2 пунктның егерме өченче абзацында «Интернет» сүзен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.3 пунктта:

14 пунктчада «Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан

Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктчада «, Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 18 пунктча өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «18. Инновация эшчәнлеге субъектларының (югары һөнәри белем бирү учреждениеләре, фәнни-тикшеренү оешмалары, инновация инфраструктурасы һәм предприятиеләр), нәтиҗәле хезмәттәшлеген һәм координациясен тәэмин итә торган механизм эшләргә, норматив-хокукый һәм мәгълүмати характердагы чараларны гамәлгә ашыруны да кертеп | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, югары һөнәри белем бирү учреждениеләре, фәнни-тикшеренү оешмалары, инновация инфраструктурасы һәм предприятиеләр (килешү буенча), тармак министрлыклары, Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2012 ел»; |

е) 3.5 бүлекчәнең 3.5.3 пунктындагы 2 пунктчасында «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 3.6 бүлекчәнең 3.6.3 пунктында:

2 пунктчада «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга, «2011 ел» сүзләрен «2012 ел» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен «тармак министрлыклары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 – 12 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «10. Муниципаль берәмлек территориясендә төзекләндерү һәм инфраструктураны үстерү проектларын гамәлгә ашыруда гражданнарның катнашу механизмын эшләргә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, тармак министрлыклары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2012 ел |
| 11. Татарстан Республикасының кече шәһәрләрен үстерү программасын эшләргә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2012 – 2013 еллар |
| 12. Татарстан Республикасының авыл торак пунктларын үстерү һәм авыл җирлегендә эшләү өчен яшь белгечләрне җәлеп итү программасын эшләргә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2012 – 2013 еллар»; |

з) 3.7 бүлекчәнең 3.7.3 пунктында:

7 пунктчада «Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктчада «2011 елның 3 кварталы» сүзләрен «2012 ел» сүзләренә алмаштырырга;

и) 3.8 бүлекчәнең 3.8.3 пунктында:

3 пунктчада «Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктчада «Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

к) 3.9 бүлекчәнең 3.9.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «4. Татарстан Республикасында Инвестиция советын төзү турында норматив хокукый акт проектын эшләргә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2012 ел»; |

л) 3.11 бүлекчәнең 3.11.3 пунктындагы 8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «8.Территориаль үсеш планнары һәм коммунальчелтәр инфраструктурасын үстерү программалары белән интеграцияләнгән торак-коммуналь комплексы оешмаларының инвестиция программаларын булдыру регламентын билгели торган норматив хокукый актлар проектларын эшләргә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2012 ел»; |

м) 3.12 бүлекчәнең 3.12.3 пунктында:

7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «7. Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтүнең һәм халыкка мәгълүмат бирүнең территориаль системасын булдырырга | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | 2012 ел»; |

9 пунктчада «, Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга, «2011 елның 4 кварталы» сүзләрен «2013 ел» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктчада «Татарстан Республикасы Энергетика министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы» сүзләренә, «2012 елның 1 кварталы» сүзләрен «2012 – 2015 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «14. Электр челтәрләренә альтернатив энергия чыганакларын тоташтыруны җайга салучы норматив хокукый акт проектын эшләргә | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы инвестиция үсеше агентлыгы | 2012 – 2015 еллар»; |

түбәндәге эчтәлекле 15 – 17 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «15. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү максатында җәмәгать транспортының экологик чиста төрләреннән файдалану программасын эшләргә | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | 2013 ел |
| 16. Предприятиеләрдә экологик идарә итү системаларын сертификацияләү һәм сәнәгать предприятиеләрендә әйләнә-тирә мохит сыйфатына идарә итү системаларына (экологик менеджментка), экологик аудитка, әйләнә-тирә мохитне тикшереп тору алымнарына кагылышлы ISO 14000 серияле халыкара стандартларны гамәлгә кертү буенча тәкъдимнәр әзерләргә | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 2012 ел |

| | | |
|---|---|---|
| 17. Әйләнә-тирә мохиткә техноген йөкләнешне киметүгә ярдәм итәрлек икенчел ресурсларны, көнкүреш калдыкларын җыю һәм эшкәртү челтәрен үстерүне кызыксындыру чаралары комплексын эшләргә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | 2012 ел». |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 19 июле
№ 57-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 975. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктында:

а) «б» пунктчасында «аңа Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләрен бирү» сүзләрен «аны Россия Федера-

циясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе) итеп сайлау» сүзләренә алмаштырырга;

б) «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) закон көченә кергән суд карары нигезендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип тану;»;

2) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ – $10^4$ статьялар өстәргә:

«$10^1$ статья. **Депутатның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр**

1. Депутат ел саен, хисап финанс чорыннан соң килүче елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба әлеге статьяда – комиссия) үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра.

2. Депутатның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләр әлеге Законның 1 нче һәм 2 нче кушымталары нигезендәге белешмәләр формалары буенча тапшырыла.

3. Депутат ел саен түбәндәгеләрне тапшыра:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан алып 31 декабрьне дә кертеп) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, бүтән түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турындагы белешмәләрне, шулай ук хисап чоры азагына милек хокукы нигезендә үзенеке булган мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне;

2) хатынының (иренең) һәм балигъ булган балаларының хисап чорында (1 гыйнвардан алып 31 декабрьне дә кертеп) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, бүтән түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турындагы белешмәләрне, шулай ук хисап чоры азагына милек хокукы

нигезендә аларныкы булган мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне.

4. Депутат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне комиссия рәисе исеменә тапшыра.

5. Депутат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрне чагылдырылмаганлыгын яисә тулысынча чагылдырылмаганлыгын ачыклаган очракта, төгәлләштерелгән белешмәләрне ул әлеге статья белән билгеләнгән тәртиптә тапшырырга хокуклы. Депутат төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң өч ай эчендә тапшырырга мөмкин.

6. Объектив сәбәпләр аркасында депутат тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмаган очракта, әлеге факт комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

$10^2$ статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясен төзү һәм аның составы**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе (алга таба – комиссия) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән төзелә, бу карар белән комиссия турындагы нигезләмә һәм аның составы раслана.

2. Комиссия тиешле чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре чорына депутатлар арасыннан җиде кешедән төзелә.

3. Комиссия составына комиссия рәисе, аның урынбасары, комиссия секретаре һәм әгъзалары керә.

4. Барлык комиссия әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия була.

10$^{3}$ статья. **Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында депутатлар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерү**

1. Комиссия әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тикшерә:

1) депутатлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

2) федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм әлеге Законда билгеләнгән чикләүләрнең һәм тыюларның депутатлар тарафыннан үтәлешен.

2. Депутатлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләргә тикшерү уздыру хакындагы карар комиссия тарафыннан кабул ителә һәм язмача рәсмиләштерелә.

3. Язмача билгеләнгән тәртиптә җитәрлек дәрәҗәдә түбәндәгеләр тарафыннан тапшырылган мәгълүмат тикшерү уздыру өчен нигез булып тора:

1) хокук саклау һәм башка дәүләт органнары;

2) сәяси партияләрнең һәм закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган башка гомумроссия иҗтимагый берләшмәләренең, шулай ук сәяси партияләрнең региональ бүлекчәләренең, региональара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең даими эшләп торучы җитәкче органнары;

3) Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

4) гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

4. Аноним характердагы мәгълүмат тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

5. Тикшерү аны уздыру турында карар кабул ителгән көннән башлап 60 көннән дә артыграк булмаган срокта гамәлгә ашырыла. Тикшерү срогы комиссия карары буенча 90 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

6. Тикшерүне гамәлгә ашырганда комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) депутат белән әңгәмә уздырырга;

2) депутат тарафыннан тапшырылган материалларны өйрәнергә;

3) депутаттан тапшырган материаллар буенча аңлатмалар алырга;

4) прокуратура органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга (алга таба – дәүләт органнары һәм оешмалар) үзләрендәге белешмәләр турында: депутатның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында; федераль законнар һәм әлеге Закон нигезендә депутат тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы турында; билгеләнгән чикләүләрнең (профессиональ даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына карата) депутат тарафыннан үтәлеше турында билгеләнгән тәртиптә гарызнамә (оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм аның нәтиҗәләренә кагылышлы гарызнамәләрдән тыш) җибәрергә;

5) физик затларны сораштырырга һәм аларның ризалыгы белән алардан мәгълүмат алырга.

7. Әлеге статьяның 6 пунктындагы 4 пунктчасында каралган гарызнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гарызнамә җибәрелә торган дәүләт органы яисә оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) нигезләнеп гарызнамә җибәрелә торган норматив хокукый акт;

3) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләре тикшерелә торган депутатның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, теркәлү, яшәү һәм (яисә) булу урыны, вазыйфасы һәм эш (хезмәт) урыны йә федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм әлеге Законда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәве турындагы белешмәләр булган депутатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, теркәлү, яшәү һәм (яисә) булу урыны, вазыйфасы һәм эш (хезмәт) урыны;

4) тикшерелергә тиешле белешмәләрнең эчтәлеге һәм күләме;

5) соратыла торган белешмәләрне тапшыру срогы;

6) гарызнамәне әзерләгән комиссия әгъзасының фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры;

7) башка кирәкле белешмәләр.

8. Адресларына гарызнамә кергән дәүләт органнарының һәм оешмаларының җитәкчеләре федераль законнар һәм

Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гарызнамәнең үтәлүен оештырырга һәм сорала торган мәгълүматны бирергә тиеш.

9. Дәүләт органнары һәм оешмалар, аларның вазыйфаи затлары гарызнамәне анда күрсәтелгән срокта үтәргә тиеш. Бу чакта гарызнамәне үтәү срогы тиешле дәүләт органына яисә оешмага кергән көннән алып 30 көннән дә артмаска тиеш. Аерым очракларда гына гарызнамәне үтәү срогы аны җибәргән затның ризалыгы белән 60 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

10. Комиссия:

1) депутатка аңа карата тикшерү башлану турында язма рәвештә хәбәр итә – тиешле карар кабул ителгән көннән башлап ике эш көне эчендә;

2) депутат мөрәҗәгать иткән очракта, аның белән әңгәмә уздыра, әңгәмә барышында аңа әлеге Закон нигезендә ул тапшырырга тиешле нинди белешмәләрне һәм билгеләнгән нинди чикләүләрнең үтәлешен тикшерү уздырылачагы турында мәгълүмат бирелергә тиеш – депутаттан мөрәҗәгать алынган көннән башлап җиде эш көне эчендә, ә мөһим сәбәп булганда – депутат белән килештерелгән срокта.

11. Тикшерү тәмамлангач, комиссия, дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәгән килеш, тикшерү нәтиҗәләре белән депутатны таныштырырга тиеш.

12. Депутат түбәндәгеләргә хокуклы:

1) язма рәвештә аңлатмалар бирергә: тикшерү барышында; әлеге статьяның 10 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча; тикшерү нәтиҗәләре буенча;

2) өстәмә материаллар тапшырырга һәм алар буенча язмача аңлатмалар бирергә;

3) әлеге статьяның 10 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча аның белән әңгәмә уздыру турындагы тиешле үтенечнамә белән комиссиягә мөрәҗәгать итәргә.

13. Әлеге статьяның 12 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына кушып куела.

14. Тикшерү нәтиҗәләре комиссиянең ачык утырышында карала, анда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре билгеләнгән тәртиптә катнаша ала.

15. Тикшерү уздыру турында карар кабул иткән комиссия аның нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә хәбәр итә.

16. Тикшерү нәтиҗәләре турындагы белешмәләр комиссия тарафыннан, бер үк вакытта үзенә карата тикшерү уздырылган депутатка хәбәр итеп, шәхси күрсәткечләр һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәгән килеш, тикшерү уздыру өчен нигез булган мәгълүматны җибәргән хокук саклау һәм башка дәүләт органнарына, сәяси партияләрнең һәм закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган башка гомумроссия иҗтимагый берләшмәләренең, шулай ук сәяси партияләрнең региональ бүлекчәләренең, региональара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең даими эшләп торучы җитәкче органнарына, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрелә.

17. Тикшерү барышында әлеге статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләрнең депутат тарафыннан дөрес яисә тулы тапшырылмавын һәм билгеләнгән чикләүләрнең үтәлмәвен таныклый торган хәлләр ачыкланганда, тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә тапшырыла.

18. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында комиссиягә кергән белешмәләрнең төп нөсхәләре, календарь ел тәмамлангач, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының кадрлар хезмәтенә җибәрелә.

19. Әлеге статьяның 18 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең күчермәләре һәм тикшерү материаллары ул тәмамланган көннән алып өч ел буена комиссиядә саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

20. Депутатның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирүе хакында комиссия тарафыннан ачыкланган мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарылырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

10[4] статья. **Депутатлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне аларның гарызнамәсенә бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе**

1. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы түбәндәге белешмәләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла:

1) милек хокукында депутатныкы, аның хатыныныкы (иренеке) һәм балигъ булмаган балаларыныкы булган яисә алар файдалануындагы күчемсез мөлкәт объектларының исемлеге, һәркайсының төрен, мәйданын һәм урнашкан илен күрсәткән килеш;

2) милек хокукында депутатныкы, аның хатыныныкы (иренеке) һәм балигъ булмаган балаларыныкы булган транспорт чараларының төре һәм маркасы күрсәтелгән исемлеге;

3) депутатның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме.

2. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында рәсми сайтта урнаштырылырга һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла торган белешмәләрдә түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

1) милек хокукында депутатныкы, аның хатыныныкы (иренеке) һәм балигъ булмаган балаларыныкы булган керемнәр һәм мөлкәт, мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы башка белешмәләрне (әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш);

2) депутат хатынының (иренең), балаларының һәм башка гаилә әгъзаларының шәхси күрсәткечләрен;

3) депутатның, аның хатынының (иренең), балаларының һәм башка гаилә әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләрне;

4) милек хокукында депутатныкы, аның хатыныныкы (иренеке), балаларыныкы һәм башка гаилә әгъзаларыныкы булган

яисә алар файдалануындагы күчемсез мөлкәт объектларының урнашкан урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләрне;

5) дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль сер булган мәгълүматны.

3. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр рәсми сайтта керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән 14 көн эчендә урнаштырыла.

4. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне рәсми сайтта урнаштыру Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Комиссия:

1) массакүләм мәгълүмат чарасыннан гарызнамә кергән көннән алып өч көн эчендә бу хакта үзенә карата гарызнамә кергән депутатка хәбәр итә;

2) массакүләм мәгълүмат чарасыннан гарызнамә кергән көннән алып җиде көн эчендә, әгәр соратыла торган белешмәләр рәсми сайтта булмаса, әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне аңа тапшыруны тәэмин итә.

6. Комиссия әгъзалары һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыруны һәм урнаштыруны тәэмин итүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре әлеге Законны үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.»;

3) 16 статьяның 1 пунктында «милек рәвешләренә бәйсез рәвештә,» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет чаралары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслаunion нучы йә гамәлгә куючылары сыйфатында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 24 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Депутат Татарстан Республикасы территориясендә аэропортларның, тимер юл һәм автомобиль вокзалларының (станцияләренең) һәм елга портларының (вокзалларының) рәсми затлар һәм делегацияләр залларыннан файдаланырга хокуклы. Халыкара һава юллары (халыкара очулар) өчен ачылган аэропортлар чикләрендә Россия Федерациясе дәүләт чиге аша үткәрү пунктларында оештырылган рәсми затлар һәм делегацияләр заллары Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә файдаланыла.»;

5) 25 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләүче һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләү өчен сайлану көненә торак урыны булмаган депутатка үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чорына аның гаризасы буенча вакытлыча файдалануга хезмәт торак урыны (җиһазлы һәм телефонлы фатир) бирелә.»;

б) 3 пунктта «аның гаризасы буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 пунктның беренче җөмләсендә «депутат вәкаләтләре туктатылган көннән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшен туктаткан көннән» сүзләренә алмаштырырга;

6) түбәндәге эчтәлекле 1 нче һәм 2 нче кушымталар өстәргә:

«1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында БЕЛЕШМӘ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
депутатлары тарафыннан керемнәре,
мөлкәте һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләре турында тапшырыла торган
белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
комиссиясе рәисе

___________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мин, ____________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының фамилиясе,
исеме, атасының исеме, туу датасы)

_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
(эш урыны һәм биләгән вазыйфасы)

_____________________________________________________________________
______________________________________________ адресы буенча яшәүче,
(яшәү урынының адресы)

20_____ елның 1 гыйнварыннан алып 20____ елның 31 декабренә кадәр хисап чорындагы үз керемнәрем, милек хокукында минеке булган мөлкәтем, банклардагы кертемнәрем, кыйммәтле кәгазьләрем турындагы, хисап чоры азагына (хисап датасына) мөлкәти характердагы йөкләмәләрем турындагы белешмәләрне хәбәр итәм:

## 1 бүлек. Керемнәр турындагы белешмәләр[1]

| № т/с | Керем төре | Керем күләме[2] (рубльләрдә) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Төп эш урыны буенча керем | |
| 2 | Педагогик эшчәнлектән керем | |
| 3 | Фәнни эшчәнлектән керем | |
| 4 | Бүтән иҗат эшчәнлегеннән керем | |
| 5 | Банклардагы һәм бүтән кредит оешмаларындагы кертемнәрдән керем | |
| 6 | Кыйммәтле кәгазьләрдән һәм коммерциячел оешмаларда катнашу өлешләреннән керем | |
| 7 | Башка керемнәр (керем төрен күрсәтергә):<br>1)<br>2)<br>3) | |
| 8 | Хисап чоры эчендә барлык керем | |

[1] Хисап чоры эчендә керемнәр (пенсияләрне, пособиеләрне, бүтән түләүләрне дә кертеп) күрсәтелә.
[2] Чит ил валютасында алынган керем, керем алу датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.

## 2 бүлек. Мөлкәт турындагы белешмәләр

### 2.1. Күчемсез мөлкәт

| №<br>т/с | Мөлкәтнең төре<br>һәм исеме | Милек төре[3] | Урнашкан<br>җире<br>(адресы) | Мәйданы<br>(кв.м) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Җир кишәрлекләре[4]:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 2 | Торак йортлар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 3 | Фатирлар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 4 | Дачалар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 5 | Гаражлар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 6 | Бүтән күчемсез мөлкәт:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |

---

[3] Милек төре (индивидуаль, уртак) күрсәтелә; уртак милек өчен милкендә мөлкәт булган бүтән затлар да (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты өлеше күрсәтелә.

[4] Җир кишәрлегенең (пайның, өлешнең) төре күрсәтелә: индивидуаль торак төзелеше өчен, дача, җиләк-җимеш бакчасы, йорт тирәсендәге, яшелчә бакчасы һәм башкалар.

## 2.2. Транспорт чаралары

| №<br>т/с | Транспорт чарасының төре<br>һәм маркасы | Милек төре[5] | Теркәлгән<br>урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Җиңел автомобильләр:<br>1)<br>2) | | |
| 2 | Йөк автомобильләре:<br>1)<br>2) | | |
| 3 | Автоприцеплар:<br>1)<br>2) | | |
| 4 | Мототранспорт чаралары:<br>1)<br>2) | | |
| 5 | Авыл хуҗалыгы техникасы:<br>1)<br>2) | | |
| 6 | Су транспорты:<br>1)<br>2) | | |
| 7 | Һава транспорты:<br>1)<br>2) | | |
| 8 | Бүтән транспорт чаралары:<br>1)<br>2) | | |

[5] Милек төре (индивидуаль, уртак) күрсәтелә; уртак милек өчен милкендә мөлкәт булган бүтән затлар да (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты өлеше күрсәтелә.

**3 бүлек. Банкларда һәм бүтән кредит оешмаларында счетлардагы акчалар турындагы белешмәләр**

| № т/с | Банк яисә бүтән кредит оешмасының атамасы һәм адресы | Счетның төре һәм валютасы[6] | Счетны ачу датасы | Счет номеры | Счетта калган өлеш[7] (рубльләрдә) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

---

[6] Счетның төре (депозит, агымдагы, исәп-хисап, ссуда һәм башкалар) һәм счетның валютасы күрсәтелә.

[7] Счетта калган өлеш хисап датасына күрсәтелә. Чит ил валютасындагы счетлар өчен калган өлеш хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.

## 4 бүлек. Кыйммәтле кәгазьләр турындагы белешмәләр

### 4.1. Акцияләр һәм коммерциячел оешмаларда бүтәнчә катнашу

| № т/с | Оешманың атамасы һәм оештыру-хокукый рәвеше[8] | Оешманың урнашкан җире (адресы) | Устав капитал[9] (рубльләрдә) | Катнашу өлеше[10] | Катнашу нигезе[11] |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |
| 5 | | | | | |

---

[8] Оешманың тулы яисә кыскартылган атамасы һәм аның оештыру-хокукый рәвеше (акционер җәмгыять, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, ширкәт, җитештерү кооперативы һәм башкалар) күрсәтелә.
[9] Устав капиталы хисап датасына оешманың гамәлгә кую документлары буенча күрсәтелә. Чит ил валютасындагы устав капиталлары өчен устав капиталы хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.
[10] Катнашу өлеше устав капиталыннан процентларда билгеләнә. Акционер җәмгыятьләр өчен шулай ук акцияләрнең номиналь хакы һәм саны күрсәтелә.
[11] Катнашу өлешен алу нигезе (гамәлгә кую шартнамәсе, хосусыйлаштыру, сатып алу, алмаштыру, бүләк итү, мирас итеп алу һәм башкалар), шулай ук тиешле шартнамәнең яисә актның реквизитлары (датасы, номеры) күрсәтелә.

### 4.2. Бүтән кыйммәтле кәгазьләр

| № т/с | Кыйммәтле кәгазь төре[12] | Кыйммәтле кәгазь чыгаручы зат | Йөкләмәнең номиналь зурлыгы (рубльләрдә) | Гомуми саны | Гомуми хакы[13] (рубль-ләрдә) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |
| 5 | | | | | |
| 6 | | | | | |

«Кыйммәтле кәгазьләр турындагы белешмәләр» 4 бүлек буенча барлыгы кыйммәтле кәгазьләрнең суммар декларацияләнгән хакы, коммерциячел оешмаларда катнашу өлешен дә кертеп (рубльләрдә) ________________________________________.

[12] Барлык кыйммәтле кәгазьләр төрләре (облигацияләр, вексельләр һәм башкалар) буенча күрсәтелә, моңа «Акцияләр һәм коммерциячел оешмаларда бүтәнчә катнашу» бүлекчәсендә күрсәтелгән акцияләр керми.
[13] Кыйммәтле кәгазьләрне сатып алу хакыннан чыгып, аларның шушы төр буенча гомуми хакы күрсәтелә (әгәр аны билгеләү мөмкин булмаса – базар хакыннан яисә номиналь хакыннан чыгып). Чит ил валютасындагы йөкләмәләр өчен хакы хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.

## 5 бүлек. Мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр

### 5.1. Файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектлары[14]

| № т/с | Мөлкәт төре[15] | Файдалану төре һәм срогы[16] | Файдалану нигезе[17] | Урнашкан җире (адресы) | Мәйданы (кв.м) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

[14] Хисап чорына күрсәтелә.
[15] Күчемсез мөлкәт төре (җир кишәрлеге, торак йорт, дача һәм башкалар) күрсәтелә.
[16] Файдалану төре (аренда, түләүсез файдалану һәм башкалар) һәм файдалану сроклары күрсәтелә.
[17] Файдалану нигезе (шартнамә, фактта бирү һәм башкалар), шулай ук тиешле шартнамәнең яисә актның реквизитлары (датасы, номеры) күрсәтелә.

### 5.2. Башка йөкләмәләр[18]

| № т/с | Йөкләмә эчтәлеге[19] | Кредитор (бурычлы зат)[20] | Барлыкка килү нигезе[21] | Йөкләмә суммасы[22] (рубльләрдә) | Йөкләмә шартлары[23] |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

«____» ______________20___ ел ____________________________________

_____________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты имзасы)

_____________________________________________________________________

(белешмәне кабул иткән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм имзасы)

---

[18] Хезмәт өчен түләүнең хисап датасына билгеләнгән 100 минималь күләменнән арткан суммага хисап датасына булган финанс характерындагы сроклы йөкләмәләре күрсәтелә.

[19] Йөкләмәнең асылы (заем, кредит һәм башкалар) күрсәтелә.

[20] Йөкләмәнең икенче ягы күрсәтелә: кредитор яисә бурычлы зат, аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (юридик затның атамасы), адресы.

[21] Йөкләмә барлыкка килү нигезе (шартнамә, акча яисә мөлкәт тапшыру һәм башкалар), шулай ук тиешле шартнамәнең яисә актның реквизитлары (датасы, номеры) күрсәтелә.

[22] Төп йөкләмәнең суммасы (процентлар суммасыннан гайре) күрсәтелә. Чит ил валютасындагы йөкләмәләр өчен сумма хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.

[23] Йөкләмәләрнең еллык процент ставкасы, йөкләмәне тәэмин итү өчен закладка салынган мөлкәт, йөкләмәне тәэмин итү өчен бирелгән гарантияләр һәм поручительлекләр күрсәтелә.

2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында**

**БЕЛЕШМӘ**[1]

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
депутатлары тарафыннан керемнәре,
мөлкәте һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләре турында тапшырыла торган
белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
комиссиясе рәисе

___________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мин, ____________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)

_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
(эш урыны һәм биләгән вазыйфасы)

_____________________________________________________________________
________________________________________________ адресы буенча яшәүче,

20_____ елның 1 гыйнварыннан алып 20____ елның 31 декабренә кадәр хисап чорында минем
_____________________________________________________________________
(хатынымның (иремнең), балигъ булмаган кызымның, балигъ булмаган улымның)
_____________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)

_____________________________________________________________________
(төп эш яисә хезмәт урыны һәм биләгән вазыйфасы; төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда – шөгыльләренең төре)

милек хокукында аныкы булган мөлкәте, банклардагы кертемнәре, кыйммәтле кәгазьләре турындагы, хисап чоры азагына (хисап датасына) мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне хәбәр итәм:

---

[1] Белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының хатынына (иренә) һәм һәр балигъ булмаган баласына белешмәләр аерым тапшырыла.

## 1 бүлек. Керемнәр турындагы белешмәләр[2]

| № т/с | Керем төре | Керем күләме[3] (рубльләрдә) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Төп эш урыны буенча керем | |
| 2 | Педагогик эшчәнлектән керем | |
| 3 | Фәнни эшчәнлектән керем | |
| 4 | Бүтән иҗат эшчәнлегеннән керем | |
| 5 | Банклардагы һәм бүтән кредит оешмаларындагы кертемнәрдән керем | |
| 6 | Кыйммәтле кәгазьләрдән һәм коммерциячел оешмаларда катнашу өлешләреннән керем | |
| 7 | Башка керемнәр (керем төрен күрсәтергә):<br>1)<br>2)<br>3) | |
| 8 | Хисап чоры эчендә барлык керем | |

[2] Хисап чоры эчендә керемнәр (пенсияләрне, пособиеләрне, бүтән түләүләрне дә кертеп) күрсәтелә.
[3] Чит ил валютасында алынган керем, керем алу датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.

## 2 бүлек. Мөлкәт турындагы белешмәләр

### 2.1. Күчемсез мөлкәт

| № т/с | Мөлкәтнең төре һәм исеме | Милек төре[4] | Урнашкан җире (адресы) | Мәйданы (кв.м) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Җир кишәрлекләре[5]:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 2 | Торак йортлар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 3 | Фатирлар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 4 | Дачалар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 5 | Гаражлар:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |
| 6 | Бүтән күчемсез мөлкәт:<br>1)<br>2)<br>3) | | | |

[4] Милек төре (индивидуаль, уртак) күрсәтелә; уртак милек өчен милкендә мөлкәт булган бүтән затлар да (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты өлеше күрсәтелә.

[5] Җир кишәрлегенең (пайның, өлешнең) төре күрсәтелә: индивидуаль торак төзелеше өчен, дача, җиләк-җимеш бакчасы, йорт тирәсендәге, яшелчә бакчасы һәм башкалар.

## 2.2. Транспорт чаралары

| № т/с | Транспорт чарасының төре һәм маркасы | Милек төре[6] | Теркәлгән урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Җиңел автомобильләр:<br>1)<br>2) | | |
| 2 | Йөк автомобильләре:<br>1)<br>2) | | |
| 3 | Автоприцеплар:<br>1)<br>2) | | |
| 4 | Мототранспорт чаралары:<br>1)<br>2) | | |
| 5 | Авыл хуҗалыгы техникасы:<br>1)<br>2) | | |
| 6 | Су транспорты:<br>1)<br>2) | | |
| 7 | Һава транспорты:<br>1)<br>2) | | |
| 8 | Бүтән транспорт чаралары:<br>1)<br>2) | | |

[6] Милек төре (индивидуаль, уртак) күрсәтелә; уртак милек өчен милкендә мөлкәт булган бүтән затлар да (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты өлеше күрсәтелә.

**3 бүлек. Банкларда һәм бүтән кредит оешмаларында счетлардагы акчалар турындагы белешмәләр**

| № т/с | Банк яисә бүтән кредит оешмасының атамасы һәм адресы | Счетның төре һәм валютасы[7] | Счетны ачу датасы | Счет номеры | Счетта калган өлеш[8] (сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

[7] Счетның төре (депозит, агымдагы, исәп-хисап, ссуда һәм башкалар) һәм счетның валютасы күрсәтелә.
[8] Счетта калган өлеш хисап датасына күрсәтелә. Чит ил валютасындагы счетлар өчен калган өлеш хисап датасына Россия Банкы курсы буенча сумнарда күрсәтелә.

## 4 бүлек. Кыйммәтле кәгазьләр турындагы белешмәләр

### 4.1. Акцияләр һәм коммерциячел оешмаларда бүтәнчә катнашу

| № т/с | Оешманың атамасы һәм оештыру-хокукый рәвеше[9] | Оешманың урнашкан җире (адресы) | Устав капиталы[10] (рубльләрдә) | Катнашу өлеше[11] | Катнашу нигезе[12] |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |
| 5 | | | | | |

[9] Оешманың тулы яисә кыскартылган атамасы һәм аның оештыру-хокукый рәвеше (акционер җәмгыять, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, ширкәт, җитештерү кооперативы һәм башкалар) күрсәтелә.

[10] Устав капиталы хисап датасына оешманың гамәлгә кую документлары буенча күрсәтелә. Чит ил валютасындагы устав капиталлары өчен устав капиталы хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.

[11] Катнашу өлеше устав капиталыннан процентларда белдерелә. Акционер җәмгыятьләр өчен шулай ук акцияләрнең номиналь хакы һәм саны күрсәтелә.

[12] Катнашу өлешен алу нигезе (гамәлгә кую шартнамәсе, хосусыйлаштыру, сатып алу, алмаштыру, бүләк итү, мирас итеп алу һәм башкалар), шулай ук тиешле шартнамәнең яисә актның реквизитлары (датасы, номеры) күрсәтелә.

### 4.2. Бүтән кыйммәтле кәгазьләр

| № т/с | Кыйммәтле кәгазь төре[13] | Кыйммәтле кәгазь чыгаручы зат | Йөкләмәнең номиналь зурлыгы (рубльләрдә) | Гомуми саны | Гомуми хак[14] (рубль-ләрдә) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |
| 5 | | | | | |
| 6 | | | | | |

«Кыйммәтле кәгазьләр турындагы белешмәләр» 4 бүлек буенча барлыгы кыйммәтле кәгазьләрнең суммар декларацияләнгән хакы, коммерциячел оешмаларда катнашу өлешен дә кертеп (рубльләрдә) ________________________________________________________________________.

---

[13] Барлык кыйммәтле кәгазьләр төрләре (облигацияләр, вексельләр һәм башкалар) буенча күрсәтелә, моңа «Акцияләр һәм коммерциячел оешмаларда бүтәнчә катнашу» бүлекчәсендә күрсәтелгән акцияләр керми.

[14] Кыйммәтле кәгазьләрне сатып алу хакыннан чыгып, аларның шушы төр буенча гомуми хакы күрсәтелә (әгәр аны билгеләү мөмкин булмаса – базар хакыннан яисә номиналь хакыннан чыгып). Чит ил валютасындагы йөкләмәләр өчен хакы хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.

## 5 бүлек. Мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр

### 5.1. Файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектлары[15]

| № т/с | Мөлкәт төре[16] | Файдалану төре һәм срогы[17] | Фай-далану нигезе[18] | Урнаш-кан җире (адресы) | Мәйданы (кв.м) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

[15] Хисап чорына күрсәтелә.
[16] Күчемсез мөлкәт төре (җир кишәрлеге, торак йорт, дача һәм башкалар) күрсәтелә.
[17] Файдалану төре (аренда, түләүсез файдалану һәм башкалар) һәм файдалану сроклары күрсәтелә.
[18] Файдалану нигезе (шартнамә, фактта бирү һәм башкалар), шулай ук тиешле шартнамәнең яисә актның реквизитлары (датасы, номеры) күрсәтелә.

### 5.2. Башка йөкләмәләр[19]

| № т/с | Йөкләмә эчтәлеге[20] | Кредитор (бурычлы зат)[21] | Барлыкка килү нигезе[22] | Йөкләмә суммасы[23] (рубльләрдә) | Йөкләмә шартлары[24] |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

«____» ______________20___ ел ____________________________________

_________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты имзасы)

_________________________________________________________________
(белешмәне кабул иткән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм имзасы)

---

[19] Хезмәт өчен түләүнең хисап датасына билгеләнгән 100 минималь күләменнән арткан суммага хисап датасына булган финанс характерындагы сроклы йөкләмәләре күрсәтелә.
[20] Йөкләмәнең асылы (заем, кредит һәм башкалар) күрсәтелә.
[21] Йөкләмәнең икенче ягы күрсәтелә: кредитор яисә бурычлы зат, аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (юридик затның атамасы), адресы.
[22] Йөкләмә барлыкка килү нигезе (шартнамә, акча яисә мөлкәт тапшыру һәм башкалар), шулай ук тиешле шартнамәнең яисә актның реквизитлары (датасы, номеры) күрсәтелә.
[23] Төп йөкләмәнең суммасы (процентлар суммасыннан гайре) күрсәтелә. Чит ил валютасындагы йөкләмәләр өчен сумма хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.
[24] Йөкләмәләрнең еллык процент ставкасы, йөкләмәне тәэмин итү өчен закладка салынган мөлкәт, йөкләмәне тәэмин итү өчен бирелгән гарантияләр һәм поручительлекләр күрсәтелә.».

**Статья 2**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) закон көченә кергән суд карары белән билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылуга, хәбәрсез югалган яисә вафат булган дип игълан ителүгә;»;

б) 8 пунктта «азат итүгә» сүзләреннән соң «, шул исәптән ышаныч югалтуга» сүзләрен өстәргә;

2) 8 статьяда:

а) беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын» сүзләрен «1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның кыйммәтле кәгазьләргә, акцияләргә (катнашу өлешләренә, оешмаларның устав (җыелма) капиталларындагы пайларга) ия булуы мәнфәгатьләр конфликтына китергән яисә китерергә мөмкин булган очракта, үзенеке булган кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (катнашу өлешләрен, оешмаларның устав (җыелма) капиталларындагы пайларны) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга;»;

в) 9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасының даими нигездә биләнүче дәүләт вазыйфасын биләүче зат үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, шулар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнгән тәртиптә тапшырырга тиеш.»;

3) 9 статьяда «Россия Федерациясе Хөкүмәте әгъзалары өчен билгеләнгән» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның җаваплылыгы**

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен, шулай ук гражданнар хокукларын һәм ирекләрен боза торган гамәлләр кылган яисә гамәл кылмаган өчен законнарда каралган җаваплылыкка тартыла.

2. Татарстан Республикасының даими нигездә биләнүче дәүләт вазыйфаларын биләүче, коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарда билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм йөкләмәләрне бозган затлар федераль законда каралган җаваплылыкка тартыла.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 19 июле
№ 58-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 976. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешма ябылуга йә физик затларның индивидуаль эшкуарлар буларак эшчәнлекләре туктауга бәйле рәвештә эштән азат ителгән, бала туугa һәм аны карауга бәйле рәвештә эшендә өзеклек булган хатын-кызлар;»;

2) 3 статьяда:

а) 2 өлешнең 1 пунктын көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә вазыйфага сайлап кую, тиешле вазыйфаны биләүгә конкурс буенча сайлап алу, вазыйфага билгеләнү яисә вазыйфага раслану юлы белән биләнә торган вазыйфалар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар хезмәткәрләренең исемлектәге уртача санына керми.»;

3) 4 статьяның 1 өлешендә «оешмалардан тыш, оешмаларда» сүзләрен «оешмалардан тыш, эш бирүчеләрдә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «оешмаларда» сүзен «эш бирүчеләрдә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «оешмаларга» сүзен «эш бирүчеләргә» сүзләренә, «оешма хезмәткәрләренең» сүзләрен «эш бирүче хезмәткәрләренең» сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «башка оешмаларда» сүзләрен «башка эш бирүчеләрдә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 20 июле
№ 59-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 977. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Җиңел такси буларак куллану күздә тотыла торган транспорт чараларын мөрәҗәгать итүченең нинди хокукый нигездә биләвенә карамастан, бер транспорт чарасына карата бер генә рөхсәт бирелергә мөмкин.»;

б) 3 өлештә «срогын,» сүзеннән соң «гариза бирү тәртибен,» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 5 статьяда:

а) статья исемендә «тикшереп тору» сүзләрен «региональ дәүләт тикшереп торуы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Федераль законның 9 статьясындагы $1^4$ һәм 16 өлешләрендә һәм әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан үтәүне региональ дәүләт тикшереп торуы вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла (күрсәтелгән таләпләрне үтәүне турыдан-туры җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу процессында тикшереп торудан гайре).»;

в) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Федераль законның 9 статьясындагы $1^4$ һәм 16 өлешләрендә һәм әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан үтәүне региональ дәүләт тикшереп торуының әлеге статья белән җайга салынмаган тәртибенә карата, Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, «Дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшереп торуны гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 20 июле
№ 60-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 978. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4; 2002, № 12 (II өлеш); 2003, № 6; 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 4; 2009, № 1; 2011, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның дүртенче, алтынчы һәм җиденче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ статья өстәргә:

«$6^1$ статья. **Нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге**

Нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан тиешенчә Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 елның 24 июнендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктының бишенче, җиденче һәм сигезенче абзацларын, 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 6);

2) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 16 декабрендәге 128-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 20 июле
№ 61-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 979. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 8 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) исемендә «Министрлар Кабинеты» сүзләрен «башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «1. Халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

в) уникенче абзацта «кирәк очракта» сүзләреннән соң «федераль» сүзен өстәргә;

г) унөченче һәм ундүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм зарарсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә үз компетенциясе чикләрендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру;

азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм зарарсызлыгы, халыкның сәламәтлеге мониторингын үз компетенциясе чикләрендә үткәрү;»;

д) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарының, аларның санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булса, чикләрен һәм режимын билгеләү.»;

е) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ул вәкаләт биргән органы (органнары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2) 4 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 6 статьяның 2 өлешендә «мониторингы» сүзеннән соң «федераль» сүзен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 20 июле
№ 62-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 980. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 19 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның беренче абзацында «Пенсиядәге» сүзен төшереп калдырырга;

2) 7 статьяның беренче абзацында «пенсиядәге» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 20 июле
№ 63-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 981. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышы каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышы каравына түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1370-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

2. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4400-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4393-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

4. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5394-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

5. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5395-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 6375-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2399-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме турында» 7404-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турында нотык.

11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында.

12. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү турында.

13. «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү турында.

14. Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Елизаветино авылының исемен үзгәртү турында.

15. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 62372-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 66075-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның аерым нигезләмәсен төгәлләштерү өлешендә).

17. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 67447-6 номерлы федераль закон проекты турында (нефть продуктлары әйләнеше өлкәсендә планлы тикшерүләр үткәрүнең даимилеген арттыру турында).

18. «Электр белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә тарифлар белән җайга салуны камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына

үзгәрешләр кертү хакында» 82041-6 номерлы федераль закон проекты турында.

19. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проекты хакында (файдалануга тапшырылган күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген тәртипкә салу һәм төзелеш алып баручыга торак урынын тоткан һәм ремонтлаган өчен һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү кертүнең хокукый нигезләрен булдыру турында).

20. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 82033-6 номерлы федераль закон проекты хакында (коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын эшләүгә һәм раслауга таләпләр билгеләү өлешендә).

21. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына шәһәр төзелешен проектлау буенча региональ һәм җирле нормативлар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 86567-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

22. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

23. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексының 17 һәм 223 статьяларына төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче төзелеш алып баручыларның банкротка чыгу үзенчәлекләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

24. «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 85076-6 номерлы федераль закон проекты турында (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме кертү хакында).

25. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 62063-6 номерлы федераль закон проекты турында (1927 елның 4 сентябреннән 1945 елның 3 сентябренә кадәр чорда туган гражданнарны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында).

26. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 59048-6 номерлы федераль закон проекты турында (1931 елның 31 декабренә кадәр туган затларны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында (сугыш елларындагы эш стажын расламыйча гына).

27. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 89417-6 номерлы федераль закон проекты турында (Интернет челтәрендәге хокукка каршы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген чикләү мәсьәләсе буенча).

28. «Дару чаралары әйләнеше турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

29. «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

30. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Ярославль өлкә Думасы мөрәҗәгате хакында.

31. Инвалид бала караучы хезмәткә сәләтле эшләмәүче затларга айлык компенсация түләве күләмен арттыру мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.

32. Ювениль ревматоид артриттан интегүче балаларны ген-инженерия биологик препаратлары рәвешендәге дәвалау чаралары белән тәэмин итү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында.

33. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга, Россия Федерациясе Эчке эшләр министры В.А. Колокольцевка һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының 2011 елның 23 декабрендәге 1298 номерлы боерыгы белән расланган һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш

министрлыгы белән килештерелгән Алкогольдән, наркотиклардан яисә бүтән агулы матдәләрдән исергән һәм мөстәкыйль йөрү яисә әйләнә-тирә вәзгыятьне аңлау сәләтен югалткан килеш җәмәгать урыннарында булган затларны медицина оешмаларына илтеп кую тәртибе турындагы инструкциягә үзгәрешләр кертү зарурлыгы хакында).

34. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2284-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 982. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6372-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6372-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2285-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 983. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (6372-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (6372-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2286-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 984. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (1370-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (1370-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2287-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 985. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4400-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2288-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 986. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4400-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (4400-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2289-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 987. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4393-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4393-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2290-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 988. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (4393-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Та-

тарстан Республикасы законын (4393-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Әлеге законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2291-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 989. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5394-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5394-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2292-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 990. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (5394-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (5394-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2293-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 991. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5395-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 5395-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2294-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 992. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (5395-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (5395-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2295-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 993. «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 6375-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 6375-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2296-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 994. «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (6375-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм

7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (6375-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2297-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 995. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2399-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2399-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 5 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 5 сентябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2298-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 996. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 6398-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 5 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 5 сентябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2299-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 997. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме турында» 7404-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Казан (Идел буе) федераль университеты»

югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме турында» 7404-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2012 елның 5 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2012 елның 5 сентябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2300-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 998. Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы нотык хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы нотык хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусев чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары тәкъдимнәрен гомумиләштергәннән соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы нотыкны (алга таба – Нотык) хупларга.

2. Нотыкны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзаларына – Татарстан Республикасыннан вәкилләргә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Татарстан Республикасыннан сайланган депутатларына, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару

(вәкиллекле) органнарына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Аппаратының Хокук идарәсенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы закон чыгару инициативасы хокукы субъектларына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын төзегәндә Нотыктагы рекомендацияләрне исәпкә алуны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре Л.Н. Мавринага Нотыкны брошюралар рәвешендә татар һәм рус телләрендә бастырып чыгаруны һәм аларның электрон күчермәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыруны оештырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2301-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 999. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе турында» 2009 елның 22 апрелендәге 86-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

икенче абзацта «алты» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясеннән Миңнуллин Туфан Габдулла улын чыгарырга.

2. «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарының эшчәнлеген камилләштерү һәм эш нәтиҗәләрен арттыру турында» 2009 елның 22 апрелендәге 94-IV ДС номер-

лы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 5 пунктында «Кузьмина Л.В.» сүзләрен «Исаева А.Г.» сүзләренә алмаштырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2302-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1000. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Эшчәнлекне камилләштерү һәм эшнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставын федераль законнарга туры китерү зарурлыгына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2005 елның 3 ноябрендәге 1696-III ДС номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 3 ноябрендәге 1844-р күрсәтмәсе белән расланган «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11) кушымта итеп бирелүче үзгәрешләрне расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2303-IV ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2012 елның 5 июлендәге
2303-IV ДС номерлы карарына
кушымта

**«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставына үзгәрешләр**

1) исемендә «дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 бүлектә:

а) 1.1 пунктта «дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Газетаның гамәлгә куючылары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – Гамәлгә куючылар).

Редакциянең гамәлгә куючысы һәм мөлкәт милекчесе – Татарстан Республикасы. Гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган) законнар нигезендә башкара.»;

в) 1.5 – 1.7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Редакция 1918 елда оештырылган «Эш» газетасының һәм «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан», «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан» газеталарының хокук дәвамчысы булып тора. Юридик зат буларак Редакция Казан шәһәре Ленин районы администрациясе башлыгының 1991 елның 25 декабрендәге 1789 номерлы карары белән теркәлгән.

1.6. Редакциянең тулы исеме – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе.

1.7. Редакциянең кыскартылган исеме – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» ТР ДБУ.»;

г) 1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Редакциянең урнашкан урыны һәм почта адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академиклар ур., 2 йорт.»;

д) 1.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.13. Редакция дәүләт йөкләмәсе һәм (яисә) мәҗбүри социаль иминләштерү буенча иминиятче алдындагы бурычлары нигезендә аның төп эшчәнлек төрләренә карый торган эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле эшчәнлекне әлеге Уставның 1.1 пунктында билгеләнгән максат нигезендә гамәлгә ашыра. Редакциянең дәүләт йөкләмәсен гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган төзи һәм раслый. Редакция дәүләт йөкләмәсен башкарудан баш тартырга хокуклы түгел.

Редакция, билгеләнгән дәүләт йөкләмәсеннән тыш, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда куелган дәүләт йөкләмәсе чикләрендә гражданнар һәм юридик затлар өчен түләүле һәм бер үк хезмәтләр өчен бертигез шартларда әлеге Уставта каралган төп эшчәнлек төрләренә карый торган эшләр башкарырга, хезмәтләр күрсәтергә хокуклы.

Редакция үзенең төп эшчәнлек төрләренә карамаган башка төр эшчәнлекне бары тик әлеге Уставның 1.1 пунктында күрсәтелгән аның төзелү максатына ирешерлек дәрәҗәдә генә һәм куелган максатка туры килсә генә, әгәр мондый эшчәнлек әлеге Уставта күрсәтелгән булса, гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

3) 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр эшчәнлекнең аерым төрләре законнар нигезендә лицензияләнергә тиеш булса, Редакция эшчәнлекнең мондый төрләрен тиешле лицензия алганнан соң гамәлгә ашырырга мөмкин.»;

4) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Редакциянең чаралары һәм мөлкәте

3.1. Редакциянең мөлкәте Татарстан Республикасы милке була, Редакциягә оператив идарә итү хокукында беркетелә һәм аның мөстәкыйль балансында чагылдырыла. Беркетелгән мөлкәткә карата милекче вәкаләтләрен дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма органы гамәлгә ашыра.

Редакциянең устав бурычларын үтәү өчен кирәкле җир кишәрлеге аңа даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукында бирелә.

3.2. Редакция тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү, гамәлгә куючы тарафыннан Редакциягә беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә алынган күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне тотуга чыгымнарны, салым салу объекты булып танылы торган тиешле мөлкәткә, җир кишәрлекләренә салымнар түләүгә чыгымнарны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3.3. Редакция мөлкәтен барлыкка китерә торган чыганаклар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Гамәлгә куючылардан даими һәм бер мәртәбә керә торган керемнәр;

ихтыярый мөлкәти взнослар һәм иганәләр;

законнарда тыелмаган башка керемнәр.

3.4. Гамәлгә куючы тарафыннан Редакциягә беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә алынган күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне гамәлгә куючы рөхсәте белән арендага биргән очракта, гамәлгә куючы мондый мөлкәтне тотуны финанс белән тәэмин итми.

3.5. Редакция Федераль казначылыкның территориаль органында яисә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачыла торган шәхси счетлар аша Россия Федерациясе законнары нигезендә керә торган акчалар белән операцияләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

3.6. Редакция, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, үз акчаларын кредит оешмаларында депозитларга урнаштырырга, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән алыш-бирешләр башкарырга хокуклы түгел.

3.7. Редакция милекче тарафыннан аңа беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә Редакция тарафыннан алынган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт, шулай ук күчемсез мөлкәт белән милекче ризалыгыннан башка эш итәргә хокуклы түгел.

Оператив идарә хокукындагы башка мөлкәт белән Редакция мөстәкыйль эш итәргә хокуклы.

Редакциянең мөлкәт милекчесе аның йөкләмәләре буенча җаваплы булмый.

3.8. Әлеге Уставта каралган максатларга ирешү өчен Редакция коммерциягә карамаган оешмалар төзергә мөмкин. Редакция милекче ризалыгы белән коммерциягә карамаган оешмаларга аларның гамәлгә куючысы буларак акча һәм, милекче тарафыннан аңа беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен милекче тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә Редакция тарафыннан алынган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәттән тыш, башка мөлкәт тапшырырга хокуклы.

3.9. Акчалар белән эш итүгә, башка мөлкәтне читләштерүгә, шулай ук мондый мөлкәтне файдалануга яисә залогка тапшыруга бәйле зур күләмле алыш-бирешне, әгәр мондый алыш-бирешнең хакы йә читләштерелә яисә тапшырыла торган мөлкәтнең бәясе Редакция активларының баланс хакыннан 10 проценттан артыграк булса, Редакция бары тик гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган белән алдан килештереп кенә башкарырга мөмкин.

3.10. Редакциянең федераль законнар нигезендә мөстәкыйль эш итәргә хокукы булган мөлкәтне арендага бирүдән, сатудан керемнәре, керем китерә торган эшчәнлектән керемнәре белән Редакция мөстәкыйль эш итә.

3.11. Редакция мөлкәт турында, шул исәптән керем китерә торган эшчәнлектән алынган керемнәр исәбенә сатып алынганнары турында да, мөлкәт милекчесенә, Гамәлгә куючыларга һәм гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органга белешмәләр бирергә тиеш.»;

5) 4 бүлектә:

а) 4.2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Редакция тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итәргә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Редакциянең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау тәртибен Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан урнаштырылган таләпләр нигезендә билгеләргә.»;

б) 4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«законнар һәм әлеге Устав нигезендә дәүләт йөкләмәсен үтәргә.»;

6) 7 бүлектә:

а) 7.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Әлеге Уставның 5, 7, 8 бүлекләре, журналистлар коллективы – Редакциянең штаттагы хезмәткәрләре составының кимендә өчтән икесе булганда, аларның күпчелек тавышы белән кабул итела һәм Гамәлгә куючылар тарафыннан раслана.»;

б) 7.2 пунктта «Уставка» сүзеннән соң «әлеге Уставның 5, 7, 8 бүлекләре нигезләмәләре өлешендә» сүзләрен өстәргә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1001. «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертү турында

Эшчәнлекне камилләштерү һәм эшнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставын федераль законнарга туры китерү зарурлыгына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2005 елның 3 ноябрендәге 1697-III ДС номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 3 ноябрендәге 1845-р күрсәтмәсе белән расланган «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениесе Уставына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11) кушымта итеп бирелүче үзгәрешләрне расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2304-IV ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2012 елның 5 июлендәге
2304-IV ДС номерлы карарына
кушымта

**«Республика Татарстан» газетасы редакциясе»**
**дәүләт учреждениесе Уставына**
**үзгәрешләр**

1) исемендә «дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 бүлектә:

а) 1.1 пунктта «дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Газетаның гамәлгә куючылары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – Гамәлгә куючылар).

Редакциянең гамәлгә куючысы һәм мөлкәт милекчесе – Татарстан Республикасы. Гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган) законнар нигезендә башкара.»;

в) 1.5 – 1.7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Редакция 1917 елда оештырылган «Знамя революции» газетасының һәм «Знамя труда», «Известия», «Известия ТатЦИКа», «Красная Татария», «Советская Татария» газеталарының хокук дәвамчысы булып тора. Юридик зат буларак Редакция Казан шәһәре Ленин районы администрациясе башлыгының 1992 елның 23 гыйнварындагы 55 номерлы карары белән теркәлгән.

1.6. Редакциянең тулы исеме – «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе.

1.7. Редакциянең кыскартылган исеме – «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» ТР ДБУ.»;

г) 1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Редакциянең урнашкан урыны һәм почта адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академиклар ур., 2 йорт.»;

д) 1.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.13. Редакция дәүләт йөкләмәсе һәм (яисә) мәҗбүри социаль иминләштерү буенча иминиятче алдындагы бурычлары нигезендә аның төп эшчәнлек төрләренә карый торган эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле эшчәнлекне әлеге Уставның 1.1 пунктында билгеләнгән максат нигезендә гамәлгә ашыра. Редакциянең дәүләт йөкләмәсен гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган төзи һәм раслый. Редакция дәүләт йөкләмәсен башкарудан баш тартырга хокуклы түгел.

Редакция, билгеләнгән дәүләт йөкләмәсеннән тыш, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда куелган дәүләт йөкләмәсе чикләрендә гражданнар һәм юридик затлар өчен түләүле һәм бер үк хезмәтләр өчен бертигез шартларда әлеге Уставта каралган төп эшчәнлек төрләренә карый торган эшләр башкарырга, хезмәтләр күрсәтергә хокуклы.

Редакция үзенең төп эшчәнлек төрләренә карамаган башка төр эшчәнлекне бары тик әлеге Уставның 1.1 пунктында күрсәтелгән аның төзелү максатына ирешерлек дәрәҗәдә генә һәм куелган максатка туры килсә генә, әгәр мондый эшчәнлек әлеге Уставта күрсәтелгән булса, гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

3) 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр эшчәнлекнең аерым төрләре законнар нигезендә лицензияләнергә тиеш булса, Редакция эшчәнлекнең мондый төрләрен тиешле лицензия алганнан соң гамәлгә ашырырга мөмкин.»;

4) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Редакциянең чаралары һәм мөлкәте**

3.1. Редакциянең мөлкәте Татарстан Республикасы милке була, Редакциягә оператив идарә итү хокукында беркетелә һәм аның мөстәкыйль балансында чагылдырыла. Беркетелгән мөлкәткә карата милекче вәкаләтләрен дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма органы гамәлгә ашыра.

Редакциянең устав бурычларын үтәү өчен кирәкле җир кишәрлеге аңа даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукында бирелә.

3.2. Редакция тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү, гамәлгә куючы тарафыннан Редакциягә беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә алынган күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне тотуга чыгымнарны, салым салу объекты булып танылa торган тиешле мөлкәткә, җир кишәрлекләренә салымнар түләүгә чыгымнарны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3.3. Редакция мөлкәтен барлыкка китерә торган чыганаклар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Гамәлгә куючылардан даими һәм бер мәртәбә керә торган керемнәр;

ихтыярый мөлкәти взнослар һәм иганәләр;

законнарда тыелмаган башка керемнәр.

3.4. Гамәлгә куючы тарафыннан Редакциягә беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә алынган күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне гамәлгә куючы рөхсәте белән арендага биргән очракта, гамәлгә куючы мондый мөлкәтне тотуны финанс белән тәэмин итми.

3.5. Редакция Федераль казначылыкның территориаль органында яисә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачыла торган шәхси счетлар аша Россия Федерациясе законнары нигезендә керә торган акчалар белән операцияләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

3.6. Редакция, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, үз акчаларын кредит оешмаларында депозитларга урнаштырырга, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән алыш-бирешләр башкарырга хокуклы түгел.

3.7. Редакция милекче тарафыннан аңа беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә Редакция тарафыннан алынган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт, шулай ук күчемсез мөлкәт белән милекче ризалыгыннан башка эш итәргә хокуклы түгел.

Оператив идарә хокукындагы башка мөлкәт белән Редакция мөстәкыйль эш итәргә хокуклы.

Редакциянең мөлкәт милекчесе аның йөкләмәләре буенча җаваплы булмый.

3.8. Әлеге Уставта каралган максатларга ирешү өчен Редакция коммерциягә карамаган оешмалар төзергә мөмкин. Ре-

дакция милекче ризалыгы белән коммерциягә карамаган оешмаларга аларның гамәлгә куючысы буларак акча һәм, милекче тарафыннан аңа беркетелгән яисә мөлкәт сатып алу өчен милекче тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар исәбенә Редакция тарафыннан алынган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәттән тыш, башка мөлкәт тапшырырга хокуклы.

3.9. Акчалар белән эш итүгә, башка мөлкәтне читләштерүгә, шулай ук мондый мөлкәтне файдалануга яисә залогка тапшыруга бәйле зур күләмле алыш-бирешне, әгәр мондый алыш-бирешнең хакы йә читләштерелә яисә тапшырыла торган мөлкәтнең бәясе Редакция активларының баланс хакыннан 10 проценттан артыграк булса, Редакция бары тик гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган белән алдан килештереп кенә башкарырга мөмкин.

3.10. Редакциянең федераль законнар нигезендә мөстәкыйль эш итәргә хокукы булган мөлкәтне арендага бирүдән, сатудан керемнәре, керем китерә торган эшчәнлектән керемнәре белән Редакция мөстәкыйль эш итә.

3.11. Редакция мөлкәт турында, шул исәптән керем китерә торган эшчәнлектән алынган керемнәр исәбенә сатып алынганнары турында да, мөлкәт милекчесенә, Гамәлгә куючыларга һәм гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органга белешмәләр бирергә тиеш.»;

5) 4 бүлектә:

а) 4.2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Редакция тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итәргә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Редакциянең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау тәртибен Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан урнаштырылган таләпләр нигезендә билгеләргә.»;

б) 4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«законнар һәм әлеге Устав нигезендә дәүләт йөкләмәсен үтәргә.»;

6) 7 бүлектә:

а) 7.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Әлеге Уставның 5, 7, 8 бүлекләре, журналистлар коллективы – Редакциянең штаттагы хезмәткәрләре составының

кимендә өчтән икесе булганда, аларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Гамәлгә куючылар тарафыннан раслана.»;

б) 7.2 пунктта «Уставка» сүзеннән соң «әлеге Уставның 5, 7, 8 бүлекләре нигезләмәләре өлешендә» сүзләрен өстәргә.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1002. Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Елизаветино авылының исемен үзгәртү турында

«Географик объектлар атамалары турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 7 һәм 9 статьялары, «Татарстан Республикасының административ-территориаль корылышы турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4, 5 һәм 10 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының Елизаветино авылының исемен Иннополис итеп үзгәртү турындагы тәкъдимен хупларга.

2. Әлеге карарны авылның исемен үзгәртүне нигезли торган материаллар һәм документлар белән Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенә экспертиза үткәрү өчен җибәрергә.

3. Экспертиза нәтиҗәләре алынганнан соң, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Елизаветино авылының исемен Иннополис итеп үзгәртү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә.

4. Күрсәтелгән авылның исеме Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан үзгәртелгәннән соң, аны Татарстан Республикасының исәпкә алу белешмәләренә кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2305-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1003. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 66075-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның аерым нигезләмәсен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 66075-6 номерлы федераль закон проектын (статьяның аерым нигезләмәсен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2306-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1004. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 62372-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә хокуклы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 62372-6 номерлы федераль закон проектын (административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә хокуклы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2307-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1005. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 67447-6 номерлы федераль закон проекты турында (нефть продуктлары әйләнеше өлкәсендә планлы тикшерүләр үткәрүнең даимилеген арттыру турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 67447-6 номерлы федераль закон проектын (нефть продуктлары әйләнеше өлкәсендә планлы тикшерүләр үткәрүнең даимилеген арттыру турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2308-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1006. «Электр белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә тарифлар белән җайга салуны камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 82041-6 номерлы федераль закон проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Электр белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә тарифлар белән җайга салуны камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 82041-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2309-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1007. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проекты хакында (файдалануга тапшырылган күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген тәртипкә салу һәм төзелеш алып баручыга торак урынын тоткан һәм ремонтлаган өчен һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү кертүнең хокукый нигезләрен булдыру турында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 52050-6 номерлы федераль закон проектын

(файдалануга тапшырылган күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген тәртипкә салу һәм төзелеш алып баручыга торак урынын тоткан һәм ремонтлаган өчен һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү кертүнең хокукый нигезләрен булдыру турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2310-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1008. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 82033-6 номерлы федераль закон проекты хакында (коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын эшләүгә һәм раслауга таләпләр билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 82033-6 номерлы федераль закон проектын (коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын эшләүгә һәм раслауга таләпләр билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2311-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1009. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына шәһәр төзелешен проектлау буенча региональ һәм җирле нормативлар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 86567-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына шәһәр төзелешен проектлау буенча региональ һәм җирле нормативлар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 86567-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2312-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1010. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2313-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1011. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексының 17 һәм 223 статьяларына төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче төзелеш алып баручыларның банкротка чыгу үзенчәлекләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексының 17 һәм 223 статьяларына төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче төзелеш алып баручыларның банкротка чыгу үзенчәлекләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Ярославль өлкә Думасына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2314-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1012. «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 85076-6 номерлы федераль закон проекты турында (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме кертү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 85076-6 номерлы федераль закон проектын (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме кертү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2315-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1013. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 62063-6 номерлы федераль закон проекты турында (1927 елның 4 сентябреннән 1945 елның 3 сентябренә кадәр чорда туган гражданнарны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 62063-6 номерлы федераль закон проектын (1927 елның 4 сентябреннән 1945 елның 3 сентябренә кадәр чорда туган гражданнарны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2316-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1014. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 59048-6 номерлы федераль закон проекты турында (1931 елның 31 декабренә кадәр туган затларны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында (сугыш елларындагы эш стажын расламыйча гына)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 59048-6 номерлы федераль закон проектын (1931 елның 31 декабренә кадәр туган затларны Бөек Ватан сугышы ветераннары категориясенә кертү хакында (сугыш елларындагы эш стажын расламыйча гына) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2317-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1015. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 89417-6 номерлы федераль закон проекты турында (Интернет челтәрендәге хокукка каршы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген чикләү мәсьәләсе буенча)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 89417-6 номерлы федераль закон проектын (Интернет челтәрендәге хокукка каршы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген чикләү мәсьәләсе буенча) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2318-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1016. «Дару чаралары әйләнеше турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Дару чаралары әйләнеше турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2319-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1017. «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2320-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1018. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Ярославль өлкә Думасы мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Ярославль өлкә Думасы мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Ярославль өлкә Думасына һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2321-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1019. Инвалид бала караучы хезмәткә сәләтле эшләмәүче затларга айлык компенсация түләве күләмен арттыру мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Инвалид бала караучы хезмәткә сәләтле эшләмәүче затларга айлык компенсация түләве күләмен арттыру мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2322-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1020. Ювениль ревматоид артриттан интегүче балаларны ген-инженерия биологик препаратлары рәвешендәге дәвалау чаралары белән тәэмин итү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Ювениль ревматоид артриттан интегүче балаларны ген-инженерия биологик препаратлары рәвешендәге дәвалау чаралары белән тәэмин итү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2323-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1021. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга, Россия Федерациясе Эчке эшләр министры В.А. Колокольцевка һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга, Россия Федерациясе Эчке эшләр министры В.А. Колокольцевка һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесе депутатлары мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенә һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2324-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1022. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимов гарызнамәсе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимовның вируслы гепатитларга каршы көрәш чараларын финанслау зарурлыгы турында гарызнамәсен Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры А.З. Фәрраховка җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 5 июле
№ 2325-IV ДС